РИФАТ
СӘЛАХ

# ЯШЕЛ АЙ

*Шигырьләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
С94

**Сәлах, Р.Г.**

С94 Яшел ай : шигырьләр / Рифат Сәлах ; кереш сүз авт. Л.Шәех. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 143 б.

ISBN 978-5-298-01859-3

Яшь шагыйрь Рифат Сәлахның әлеге китабында өряңа шигырьләре урын алды. Аларда сөйгән ярга, туган җиргә, табигатькә, яшәешкә мәхәббәт ярылып ята.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01859-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Сәлах Р.Г., 2009

## ШИГЪРИЯТНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ

Юл буйлап бер егет килә. Туктарга уенда да юк, каядыр чаба, каядыр ашыга ул. Елмаеп та ала, йөзендә сагыш чаткылары да сизелеп куя. Иң мөһиме, ул сагышларга артык бирелеп, җебеп төшми, егетләрчә ныклык, ирләрчә сабырлык белән горур басып атлый. Мин аның күзләренә карыйм, алар – яшел... Ә яшел төс – яшәеш, тереклек төсе. Бу күзләрдә яшьнәп яшәргә омтылу, яшьлек үзе балкый. Аның өчен ай да, Агыйдел дә, Идел дә яшел. Юкка түгел бу, бер дә юкка түгел... Бу егетнең бер кулында каләм, икенчесендә – блокнот. Күңеле тулы хис, ихлас сөю, әйтерсең лә аның бөтен җанын мәхәббәт чорнап алган. Сөйгән ярга, милләткә, газиз анага, туган йортка, ватанга...

Кем булыр икән бу?.. Хәер, үзем таныштырыйм инде. Ул – Рифат Сәлах. Алгы сафта баручы яңа, яшь буын шагыйрьләренең берсе. Аның турында сөйләгәндә, Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсен искә төшерми булмас, мөгаен.

Моннан биш ел элек Казан дәүләт университетының юридик факультеты студенты Рифат Сәлаховны «Әллүки»гә чакырдык. Бу вакытта ул яңа гына урта мәктәпне тәмамлаган оялчан гына бер егет иде. Шигырьләр яза икән, аларны укытып карады. Дөресен әйтим, нәрсәсе беләндер күңелне үзенә тартты, киләчәккә өмет уятты. Без аның әсәрләрен «Әллүки»дә тикшереп, университетта татар студентларының минем җитәкчелектә дөнья күреп килгән «Тәрәзә» газетасында бастырып чыгардык. Кереш сүздә мин болай дип язган идем: «Юридик факультетның беренче курсында талантлы гына бер егет укый. Ул «Шигъри Сабантуй» ташкыны белән дәртләнеп, илһамланып, «Әллүки»гә атылып килеп керде. Рифат Сәлахов, юрист булырга уйласа да, үзенең илаһи кыйбласыннан да тайпылырга исәбе юк. Бер җыенда аның да шигырьләрен карадык. Ни гаҗәп, «Шигърият мәйданына егетләр килми» дип ялгышабыз түгелме дигән нәтиҗәгә килдек. Рифатның шигырьләрендә мәхәббәт тә, тирән фәлсәфә дә, милләтебез язмышы өчен борчылу да бар...»

Әйе, Рифатның таланты чын-чынлап «Әллүки»дә ачылды, бөреләнде һәм чәчәк атты. Әлбәттә, ул шигъри талантын үстерү, шигърияттен камилләштерү өчен зур тырышлык күрсәтте, төрле шигъри формаларда, шигъри үлчәмнәрдә язды, экспериментлар үткәрде. Аның башкалар уйлап та карамаган диптихлары, триптихлары пәйда булды. Көндәлек матбугатта актив басыла башлады һәм, ниһаять, 2007 елда Татарстан китап нәшриятында «Күңел бөртекләре» дигән беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Аннары ул Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Нәтиҗәдә бүгенге көн яңа татар әдәбияты күгендә Рифат Сәлах дигән яшь шагыйрьнең үз йолдызы кабынды.

Рифатның бер генә шигыре дә укучыны битараф калдырмый, күңел кылларын тибрәндерә, күңелне дулкынландыра, кыбырсыта. Алай гына да түгел, бер дулкын булып үзенә алып кереп китә. Шагыйрь төрле темаларны күтәрә. Бигрәк тә ул мәхәббәт лирикасында көчле. Табышлары да байтак. Шигырьләрнең халәти үлчәмнәре, хисси контрастлары төрле: бәхетле – бәхетсез, сагышлы – сөенеч катыш, җавапсыз – нәтиҗәле, моңсу – шатлыклы, көчле – очкынланып кына торучан, тирән – җиңелчә... Аларның Рифат Сәлах каләменнән агылганын тоеп була. Димәк, шагыйрьнең үз стиле бар дигән сүз.

Рифатның милли темага кагылышлы шигырьләрендә татар тарихы һәм аны барлау, бүгенге вазгыять һәм милләтнең киләчәге турында уйлану ачык тоемлана. Ул борчыла, үз халкын горур, көчле, ирекле итеп күрергә тели.

...Юл буйлап бер егет килә. Аның мәхәббәт тулы йөрәге, шигъри җаны бар. Ул инде иҗаттан башка яши алмый, шуңа көн-төн яза, ак кәгазь буйлап каләмен биетә. Серле Шигърият иләндә үз юлын сала. Ул юл торган саен озыная. Шулай дәвам итсен. Егетебезнең бәхете булсын. Илһамы туктаусыз ташып, уйлары йолдызлы күкләргә ашып торсын! Ни генә дисәң дә, татар шигъриятенең киләчәге Рифат Сәлах кебек шәп егетләр кулында!

*Ленар Шәех*

# ЯШЕЛ АЙ НУРЫНДА



# ЯШЕЛ АЙ

*(Идиллия)*

Күктә яшел ай. Парлы ак болытлар төнге караңгылыкны ачып җибәрәләр. Ике болыт белән ай арасы зәңгәрсу төскә кергән. Айдан төшкән ап-ак күбәләк тәрәзәгә куна. Тәрәзә, җылы җәйнең иртәнге чыгын үпкән сыман, юешләнеп кала. Кар бөртеге шул минутта ук эреп күздән югала. Аның урынына башкалары, елмаяелмая, туңа башлаган пыяланы бизәклиләр. Бизәкләрдә күңел сурәте. Ул сурәт рәссам язган картинаны хәтерләтә. Ай аңа яшел буяу тамыза. Буяулар, кисәкләргә бүленеп, аерым-аерым нур нокталарына әверелеп, күзне иркәлиләр.

Моң. Бу моң – бәхет моңы. Әнә ике кар бөртеге, уйнаклаша-уйнаклаша, күкне гизә. Алар әйтерсең җиргә төшмиләр, киредән болытларына күтәреләләр.

Ай да бәхетле. Ул ялгыз түгел, янәшәсендә сөйгәне бар, шуңа сүзсез генә җире көйләгән көйне тыңлый.

Берән-сәрән калыккан йолдызлар, аулак өйгә җыелган яшьләр кебек, бер-берсенә күз кысышалар. Әле берсе, әле икенчесе болыт артына поса... аңламассың. Бәхеттән качып котылып буламыни?!

Ә җирдә, иң нечкә кылларны тибрәтеп, нидер җырлый. Әллә тимер арба тавышы, әллә кыңгырау чәчәкләре, әллә...

Каядыр ярсып-ярсып нидер дөп-дөп итә.

Тәрәзәдән яшел ай елмая. Күктә ике болыт йөзә...

Парлы болытлар!!!

## ГЫЙБАДӘТ

Аллаһ исме белән башлыйм әле! –
Изге эшләр шулай башлана.
Һәм күкләргә багып дога кылам:
«Йә Ходаем, үзең ташлама!»

Һәм диварга килеп башны куям,
Кулны куям дивар өстенә.
Бер үрмәкүч пәрәвезен үргән –
Язып куйган сыман «бисмилләһ».

Маңгаемны җир өстенә куям
Һәм ялварып сорыйм, тезләнәм.
Мин булмасам иде язмышымның
Бәхет-сынавына түзмәгән.

Һәм күкләргә багып дога кылам,
Йә Ходаем, үзең ташлама!
...Гаҗәпләнәм, әле шуннан соң да
Бәгыремдә күпме таш кала.

## БОЛГАРЫМ!

Тәүге күргән сыман каршылыйсың,
Бар иде лә монда булганым.
Меңьеллыклар, гасыр, чорлар аша
Сиңа кайтып барам, Болгарым!

Дәва эзләп синең җиргә киләм,
Сыкрый калса җанда иманым.
Һәр ташыңны, сулышыңны тоеп,
Сиңа кайтып барам, Болгарым!

Күңелемә төрәм аклыкларын
Идел өстен күмгән томанның.
Томаннарны, дулкыннарны ерып,
Сиңа кайтып барам, Болгарым!

Милли кояш сүнгән чакларда да,
Болгар җиле, рәхмәт, тынмадың.
Милләтемнең җан тибешен тоеп,
Сиңа кайтып киләм, Болгарым!

## АРХЕОЛОГИК ЭКСПЕДИЦИЯ

*(Диптих)*

**1**

Ай йөзәме күктә, кояш микән,
Әллә көн яктысы, әллә төн?..
Шундый чакта халкым югалткандыр
Илен, җанын, көчен, дәүләтен.

Офыкларны ачып карау кирәк,
Ниләр икән пәрдә артында?
Явыз Иван килеп җитәр җирдә
Әле безнең Ядгәр хан тора!

Тарихларны ерып карыйсы бер,
Анда безгә күпме ядкәр бар.
Күңел күзен йомган килеш кенә
Хан төрбәсен казый татарлар.

**2**

Күктә кояш йөзә, көне эссе,
Минут саен килә эчәсе.
Безгә әле күпме җир казыйсы –
Тарих тузаннарын ишәсе.

Тарих тузаны да ялыктыра,
Туфрагында хан йә би булсын…
Тәңкә тапсаң бер хәл, керамика... –
Моның өчен безгә ни булсын?!

Тимер әйбер тапсаң, талибенә
Бүләк тамар мөдәррисеннән.
Баш өстендә – кояш, кайный дөнья,
Котылырбыз микән эсседән?!

Каникулда җирдә казын инде,
Син тарихчы, имеш, әллә кем.
...Тарихларда гына булса да бер
Торгызыйк без татар дәүләтен!

# УЯНУ

*(Диптих)*

Татар акылы төштән соң.

*Әйтем*

## 1

Төш вакыты җитә.
Мәрткә киткән...
Йокысыннан татар уяна.
Башын күтәрә дә
Айнымаган
Сәрхуш кебек карый дөньяга.

Эш урынына соңга калган кебек,
Ул каядыр шундый ашыга.
Таныш түгел милләт балалары,
Таныш түгел йөзләр каршыда.

Юкса аңа бер гасырлап элек
«Уян!» диеп булды кычкырган.
...Кичә генә берәмтекләп җыйган
Өметләре төшкән учыннан.

Былтыр кыскан бүген кычкырмыйлар,
Кисми калды, шөкер, «Баш балта».
Иртән торгач бик ашыйсы килә –
Әнә кемдер кошлар ашата.

Йөри татар барын-югын чүпләп,
Үз өлешен эзли, көмешен.
...Үземнең дә шушы татар кебек
Өметемне эзләп килешем.

**2**

Сәрхуш көннәренә калмыйк, туган,
Сәрхуш өмете бер: ул – хәмер.
Ул да, бәлки, өмет эзләп туеп,
Онытылыр өчен эчәдер?

...Эш урынына соңга калган кебек,
Йокысыннан татар уяна.
Иле дә юк, ханы да юк аның –
Теле генә калган дөньяда.

Үз акылы кирәк булгангамы,
Уянган да хәзер төш күтә.
Бу дөньяда үз урының кирәк,
Урыныңны табу ничек тә!

Бер өмет бар, уянды бит татар,
Үз бәхетен эзли ул чыннан.
Ә өметен күңеленә салды,
Коелмасын диеп учыннан!

## ӘЙ РУСИЯ!

Әй Русия!
Син әле дә безгә
Изге Ватан кебек, үз кебек.
Нигә безгә җәза?
Милләт кими
Һәм телебез ята изелеп.

Әй Русия!
Син гаепле түгел
Безнең Ватан булган өчен дә.

Син үзең дә сыктап елыйсың бит
Дәште Кыпчак җире өстендә.

Әй Русия!
Син күп вакыт безгә
Изге Ватан юкса, үз әле...
Безнең мөшкеллеккә гафил шул син,
Һәр халыкның мөшкел үз хәле.

Әй Русия!
Син күп вакыт безгә
Изге Ватан идең, үз идең.
Үз-үзеңне үзең саклар өчен
Булсын икән җирдә үз Илең.

## ҮЗ ТЕЛЕНДӘ

Милләтләре төрле-төрле юкса,
Ник аерылмый һич тә татар рустан?
Русиягә мәгърур башын никтер
Артыграк игән Татарстан.

Русиягә кирәк түгел үзе
Баш июләр, баш бирүләр бүген.
Рөхсәт тә бар юкса, ирек тә бар,
Ник ташлады татар ана телен?

Без кол түгел, без – ирекле халык,
Ватаныбыз да бар, илебез дә.
Йөзгә туры карап сөйләү кирәк,
Сөйләшергә туган телебездә!

## ИСХАКЫЙ!

«Милләтебез!» – диеп, яныш-көеп,
Без яшәргә тиеш, без – бакый!
Дөрес юлны күрсәткәнең өчен
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, Исхакый!

Инкыйразга ике гасыр алдан
Кисәткәнсең ярый...
Без – исән!
Башны ию кирәк микән илгә,
Ватаныңда үзең изелсәң?!

Син киткәч тә, милләтебез күге
Мең каралды, мең кат аязды.
Казан урамнары истә тота
Яушырмәдән килгән Гаязны.

Казан йортларына сеңеп калган
Синең аваз булып «Азатлык!..»
Инкыйразга барса туган халкың,
Яшәвең дә җирдә газап бит.

Ләкин яшәү күпкә ләззәтлерәк,
Көтеп яту түгел казасын.
Чит илләрдә торып әле һаман
Милләтеңә хатлар язасың.

Без атларга тиеш ялгышмыйча,
Туры юлда синең эз балкый!
Син яшәсәң, яшәр милләтебез,
Ышан безгә, ышан, Исхакый!

## ОЧРАШУ

Төн уртасы.
Ишек шакый берәү.
Апрельнең соңгы көннәре.
Юкса күптән юк иде лә безгә
Тукай әфәнденең килгәне.

Ишек ачтым.
Бергә каһвә эчтек.
Төне буе шигырь сөйләде.
Ул киткәндә бер үкенеч булып
Җирдә калган икән сөйгәне.

Тынып калдык.
Тынып торды бермәл.
Ютәлләде янә, буылды.
Сораштырды: «Яшьти, ничек, – диеп, –
Сезнең Яңа гасыр буыны?»

Саубуллашты.
Юлга чыгып китте.
Бер борылып бакты – түзмәде.
Офыктагы ал таң яктысыннан
Карап тора Тукай күзләре.

## СӘЙДӘШ МУЗЕЕНДА

Ак кәчтүмнән, кара галстуктан
Яз иленә кереп калгансың.
Тормыш юлың рояль төймәседәй,
Күргәнсеңдер агын-карасын.

Кичер мине, әгәр көйләреңнең
Белеп бетермәсәм мин барын.
Яшисең син безнең күңелләрдә,
Кирәк безгә синең моңнарың.

Кичер мине, кичер, музееңа
Тәүге ташкыр гына килүем.
Күңелемдә шаулый дулкыннары
Моңлы «Әдрән диңгез» көенең.

Рояленда көй көйләргә торам,
Мин аңарда уйный белмим дә...
Чәчәк аткан сирин арасыннан
Елмаясың әле бүген дә.

Көләсеңдер рояль төймәсенә
Белер-белмәс кенә басканнан.
Тәрәзәңдә ап-ак карлар ява,
Күзләреңдә һаман яз калган.

## МӨФТИ ХӘЗРӘТКӘ

Үлгәннән соң мактату вә сагынылу – терек булу,
әмма терек вакытта мактату – үлү вә онытылу.

*Ризаэтдин Фәхретдин*

Түзеп булмас!..
Түзеп булмас янә безнең җирдә
Шайтан өермәсе калкуга.
Тел сагына – Тукай,
Дин сагына
Фәхретдине кирәк халкыма!

Кемнәрнедер артык борчыганда
Ватандагы рухи төрлелек,
Кире кайт син безгә, әй Фәхретдин,
Өр-яңадан җиргә терелеп.

Без – мохтаҗлар.
Рухның сүрән чагы.
Хаҗәт безгә иман-тәрбия.
Һичьюгында синең дәресләрең
Җитеп торыр иде әлегә.

Түзеп булмас!
Шайтан өермәсе
Илгә, телгә, дингә кул сала.
Кайт син безгә, кайтчы, мөфти хәзрәт,
Рухың белән генә булса да.

## БӘЙСЕЗЛЕК ТУРЫНДА

«Бәйсезлек!» диеп бугаз ерткачны,
Төзәтү кирәк иман-калыпны!
Аллаһ әле дә яшәтә җирдә
«Коръән серләре»н язган халыкны.

«Бәйсезлек!» диеп бугаз ерткачны,
Искә төшерик тарих-хәтерне.
Иксез һәм чиксез вакыт мизаны
«Киләчәгең бар!» диеп әйтерме?

«Бәйсезлек!» диеп бугаз ерткачны,
Яшәргә кирәк кыйбланы табып.
Үз Газраилең әле туганчы
Без дә бу җирдә өметле халык!

## ТАРКАУЛЫК

Һәр милләтнең үз сырхавы була,
Тик читнекен тоймый беркем дә.
Безнең халкыбызның язмышы да
Бездә түгел, читләр иркендә.

Балык булып, халык язмышы да
Каракоштан күпме таланды.
Ә без гафил, дәшми калырбыз күк,
Сатып эчсәләр дә ананны.

Нигә милләтебез таркау безнең?
Үзебездә йөрмик казынып!
Берләшкәннәр Нәүрүз бәйрәм итә,
Таркалганның гына язы юк.

Милләт тарафында ут җилләре,
Ничә гасыр моңа түзелгән.
Безме соң бу
Яшел яз аенда
Көйгән яфрак булып өзелгән?

Безнең язлар кире кайтыр, ләкин
Ничек берләшик бер таркалгач.
...Табаларда телсез балык...
Әнә
Утка таба сөйри табагач.

## ЧЕБЕН

Ватаныңны дошман әсир итсә,
Нинди мәгънә яну ут булып?
Чебен килеш тарих-пәрәвездән,
Чукынсаң да, булмый котылып.

Әсирлектә азык булмый инде.
Зәгыйфьләнгән милләт, әйдә, бет!
Пәрәвезгә якын килми генә
Үз вакытын көтә әнкәбүт*.

## ПОСТМОДЕРН

Гаскәр булып Үткән килә –
Кулларында – айбалта.
Тәрәзәләр яна күктә,
Әрнеп кенә ай бата.

Гаскәр булып килә бүген
Сызып ташланган Тарих.
Таң кызының толымнарын
Төн егетләре тарый.

Гаскәр булып Үткән килә,
Бүгенге тора карап.
Җирдә ята Таңсылуның
Толымы белән тарак.

---

* Ә н к ә б ү т – үрмәкүч.

# БҮГЕН

*(Триптих)*

**1**

Тагын автобуста барам,
Кузгалдым сәгать бердә.
Кая китеп баруымны
Күңелем генә белә.

Беләм инде кайтырымны
Шул ук уйларым белән.
Минутларны, секундларны
Хыялларыма бирәм.

**2**

Яктыра кара төннәр дә,
Яктыра... сүнгән таңнар.
Җиһанга чәчмәм күңелне,
Бәлки, берәрсе аңлар.

Бәлки, берәү кагылмыйча
Гына китәр уема.
...Төнге күктән тамчы булып
Хыялларым коела.

**3**

Кичә ике кояш иде,
Ә бүген... бүген ничә?
Көннәр һаман яктыра күк,
Яктыра бүгенгечә.

Хыялларым чиксез иде,
Уйларым бүген ничә?
...Йөрәк кенә үзгәралмый,
Йөрәгем – бүгенгечә.

## ЗИНДАН

Дөньяда без кем соң әле,
Танылганмы беребез?
Үз эчебезгә бикләнеп
Яшибезме бүген без?

Зилзиләләр яный әле:
«Бераз гына түзегез!»
Тоткыны да, назыйре дә,
Җәллады да үзебез!

## БӘХЕТ

Бәхет бар ул, диләр, язмыш та бар.
Беркем белә алмый язмыш эшен.
Бәхет – әгәр исән-имин булса,
Яннарыңда булса якын кешең.

Бәхет бар ул, әгәр кирәк булсаң,
Бер күтәрә алсаң халкың аңын,
Һәрбер гамәлеңнең изгелеген
Аңлый алса синең якыннарың,

Бу дөньяның гүзәллеген күреп
Шөкер итә белсәң һәммәсенә,
Бәхет-юлың, иманыңны табып,
Төшеналсаң яшәү мәгънәсенә.

## УРАЗА ГАЕТЕ

Бу җирдә динилек буласын
Оныттык без, әллә белмәдек.
Мөэминнәр яхшыга юрасын,
Хәерле булсын дип бу гает.

Мәчеттә урын юк – шау халык,
Мәҗбүрмен урамга чыгарга.
Гаеттә мәчеттән чыксам да,
Йә Раббым, иманнан чыгарма!

Хаталы укысак намазны,
Ходаем, гафу ит син, кичер.
Казасыз калмабыз,
Газаптан коткарчы
Иманга сусаган җан өчен.

Исламның яңадан калкуы,
Юл да юк – шау халык урамда.
Елына ике кат булса да,
Кайтабыз икән бит иманга.

Бу җирнең иманлы буласын
Белмәдек бугай шул, белмәдек.
Болытлар яхшыга юрасын,
Үткәч тә сүнмәсен бу гает.

Мәчеттән чыгабыз, һәркемнең
Күзләре яңгырга чылана...
Гаеттән чыксак та,
Йә Раббым,
Күңелдән иманны чыгарма!

## УРТАК ТҮБӘ

Дәмәшкъка сәяхәткә килдек,
Кунакханә эзләү – юләрлек.
Бер төрек һәм ике татар бергә
Шәһәр үзәгенә юнәлдек.

Дәмәшкъта урын эзләп йөрдек,
Белмим, кемнәр ничек эшлиләр.
Төн кунарга төрекләргә кердек,
Бар бит җирдә яхшы кешеләр!

Чәй эчмәдек, каһвә – иске нәрсә,
Заманчалап Pepsi чөмердек.
Ярый әле аңлы телебез бар,
Иркен сулап җирдә йөрерлек.

«Чакырмаган кунак – яман», – диләр... –
Без татарлар шулай диябез...
Әфәнделәр бар да уртак дия:
«Уртак күк бар – уртак түбәбез...»

Нишлисең бит, дөнья уртак нәрсә,
Бер үк Галәм, Кояш, Җиребез.
Бу дөньяда күпме яхшылык бар –
Рәхмәт әйтә белми йөрибез.

# ГАРӘПЛӘРДӘН КҮРЕП...

*(Сатирик шигырь)*

Гарәплардән гарепләргә кадәр
Дәүләте бар бөтен халыкның.
Татар дигән милләт, ник соң әле
Җир өстенә соңлап калыктың?

Гарәплардән күрәм, искитәрлек,
Йортлары да таштан, тимердән.
Егерменче гасыр азагына
Күпме дәүләт төзеп өлгергән.

Сөйләшләре саен бер дәүләт бар,
Диалект саен бар бер ил.
Татарга да иң кимендә өч-дүрт
Дәүләт төзү кирәк барыбер.

Мишәрстан булсын, Татарстан,
Башкортстан, Себерстан да.
Яшик әле кунакларга йөреп,
Кучтәнәчләр тотып дусларга.

Татар дәүләтләре берлегенә
Керик тә без бергә берләшик!
Бөтен дөнья карап торсын әле:
«Бу – татарлар!» – диеп, көнләшеп!

Бүлгәләнү безнең канга сеңгән,
Бүлгәлибез туган халыкны.
Гарәпләрне күргәч, татар өчен,
Урысчалап әйтәм, обидно!

## СҮРИЯДӘ

Кемдер өчен сәер тоеладыр,
Барсын күрә торып дәшмисең.
Юкса аек акыл,
Капмыйлар да
Сыра түгел, балның әчесен.

Булмый монда исергәнче эчү,
Булмый монда фәхеш кичәләр.
Койрык болгап күбрәк йөреп кара –
Койрыгыңны шундук кисәләр.

Кичә күргән идем аек илнең
Койрыксыз бер кара мәчесен.
Безнең өчен сәер, артык сәер,
Аек килеш дәшми яшисең.

## БАРЫП ҖИТӘРМЕ?

*Казан гүзәленә*

Барып җитәр микән хәбәрләрем,
Еракларлан сәлам юлласам?
Хат та түгел, SMS та түгел,
Еракларлан сиңа җыр язам!

Барып җитәр микән хәбәрләрем,
Аңларсыңмы икән син мине?
Еракларга китеп барды диеп,
Өметләрең инде сүндеме?

Барып җитәр микән хәбәрләрем...
Сиңа кадәр меңләп чакрым бар.

Кулларым да бүген салкын минем –
Алар сине шундый сагынган.

Барып җитәр микән хәбәрләрем –
Бик ерак шул миннән син, Казан.
Ишетерсең әле, ишетерсең,
Ераклардан сиңа җыр язам!

## СӘЯХӘТНЕҢ БЕР КӨНЕ

Эссе кояш күктән пар чыгара,
Качып ятам җиләс бүлмәдә.
Җилле булмас иде, вентилятор
Бар бүлмәне ялгыз җилгәрә.

Качып ятам гарәп дәүләтендә,
Җанга, белмим, җитми ни генә?
Ачылмаган меңләп сере белән
Озатып калыр мине Сүрия.

Күңелемдә күпме өмет иде,
Шул серләрне ачу теләге.
Өметләрем яктысында ятам,
Кочагыма кысып бүлмәне.

Эссе кояш кочагында кала
Сүриянең тылсым-серләре.
Күңелемдә гарәп кызы түгел,
Күңелемдә һаман син әле.

Чит җирләрдә кала гомеремнең
Чәчкәләргә тулган бер мәле.
Чыгып киттем синең яннарыңа,
Япа-ялгыз итеп бүлмәне.

## ДӘМӘШКЪ КҮГЕНДӘ

Мин күгеңдә синең йөзеп йөрим,
Мин күгеңдә синең, Сүрия!
Бу җиһанда тагын дөнья булса,
Бу исемгә лаек син генә.

Алда әнә төсле утлар яна,
Анда синең нурың, гүзәллек!
Алда хыял көтә.
Самолетның
Төшүенә генә түзәрлек.

Канатларны кочагыңа куйдым –
Канатларым, әйе, тимердән.
Бер мин генә түгел ансы, беләм,
Сине күрим диеп тилмергән.

Алда мине капкаларың көтә,
Йә ябык ул миңа, йә ачык.
Хыял биргән алсу канатларны
Кочагыңа салдым, Дәмәшкъ.

## ШАМ ИЛЕНДӘ

Мин бит монда бер яшәгән идем...

*Зөлфәт*

Чит-ят җирдә дисәм, алай түгел,
Таныш аваз килә уңнан-сулдан.
Шул ук пальма монда, шул ук кальга –
Мин бу җирдә бер яшәгән сыман.

Таңнары да нәкъ шул, таллары да...
Таулары да шул ук, шундый биек.
Шул ук өмет монда, шул ук кибет –
Мин бу илдә бер яшәгән кебек.

Упкыны да, дулкыны да шул ук –
Тарих җиле давылланып исте.
Урта диңгез кочагында йөзәм,
Бу дөньяда бер яшәгән төсле.

Хәтеремнең ерак почмагыннан
Эзләп йөрим Сүрия – Шам илен.
Пышын гына хәтер дәшә миңа:
«Мин бит монда бер яшәгән идем!»

## ДӘМӘШКЪ КАПКАЛАРЫ

Өр-яңадан килгән чакта
Тик синең хакка бары,
Каршы алыр безне горур
Дәмәшкъ капкалары.

Ишекләрен ачып көтәр,
Сагынып безне алар.
Карасаң, күзләр чагыла –
Әйтерсең көзге алар.

Капкада кояш чагыла...
Кояшлар безнең өчен.
...Мәхәббәттән ярсып янам –
Син генә «эссе» дисең.

## КАЛЬГАТУЛ МӘРКӘБ ТӘЭСИРЕНДӘ

Тауга менеп,
Таудан түбән төштем,
Берьялгызым гына атладым.
Мең юл чатларында басып торам,
Үз юлымны әле тапмадым.

Тауга менеп төшү берни түгел,
Шөкер, исән, тәнем сәламәт.
...Тау башында
Бөркетләрне күрсәң,
Туганнарым алар,
Сәлам әйт!

Мин бөркетләр белән озата бардым
Болытларның ярсып акканын.
Күк гөмбәзен мең кат иңләсәм дә,
Үз юлымны һаман тапмадым.

Күпме колачладым диңгез суын,
Күпме гиздем дала-чүлләрен,
Адаштырган урманнары белән
Ерак калды туган җирләрем.

...Сагынырсың син дә,
Сагынырсың
Күзләреңнең чыклы чакларын.
Кулларыңнан тотып йөгергәндә,
Син генә ул никтер чапмадың...

## ВОКЗАЛДА

Әллә нәрсә булды әле миңа –
Бер дә юктан аяк аксады.
Сәяхәткә чыгам. Озатып кала
Латакия автовокзалы.

Сәфәр көтәм. Таныш түгел җиргә
Таныш түгел җирдән кузгалам.
Аксамаган кешеләр дә инде
Җәяү йөрми торган бу заман.

Автобусны көтәм. Тезләремнең
Авыртуы хәтта онтылган.
Әллә нигә вакыт бик тиз үтә,
Кай арада инде ун тулган.

Кай арада вакыт үтеп киткән?
Аягым да инде төзәлде.
Әллә нәрсә булды әле миңа –
Көлеп тора гарәп гүзәле...

## ЮГАЛТТЫМ

Туган ягым сагындыра...
Ерак җирдә язмыш юллары.
Куенымда гына йөрткән
Блокнотым кичә югалды.

Юатырга, ичмасам, бер
Моңлы гармун да юк янымда.
Йөрәккәем түзәр микән
Шаулы диңгезләрнең ярында?

Йөрәк түзәр микән, белмим,
Туган җирдән болай ерак мин.
Куенымда гына йөрткән
Сагышымны кичә югалттым.

## САГЫНДЫМ СИНЕ, ӘНИЕМ!

Туган якта чакта гамь юк иде,
Күңел – дала иде... Ә бүген
Кош теледәй берәр хәбәр көтәм –
Мин сагындым сине, әнием!

Әллә нигә нечкә икән күңел,
Тыштан гына кырыс ул минем.
Бала булып бер назланыр идем,
Мин сагындым сине, әнием!

Нигә болай икән?
Сезне сагынып
Үтеп китә һәр төн, һәр көнем.
Мең чакрымнар аша дәшәм сиңа:
– Мин сагындым сине, әнием!

Егетләргә болай килешми дә,
Бала гына бугай әле мин.
Сабыйларча самимилек белән
Мин сагындым сине, әнием!

Чит җирләргә китү берни түгел,
Сагынулар гына әй кыен!
Сиңа сәлам юллап калам, әни:
«Мин сагындым сине, әнием!»

## ТУГАН ТУФРАК ҖЫЛЫСЫ

Еракларадан ничек итеп
Сәламнәрне юллыйсы?
Сагындыра, үзенә тарта
Туган туфрак җылысы.

Күңел тулы моңнар гына,
Җырлыйсы да җырлыйсы!
Читләргә киткәч тоела
Туган туфрак җылысы.

Кая алып китәр безне
Бу язмыш юлы – озын.
Җан өшегәч, кирәк бер уч
Туган туфрак җылысы.

Туган якның кочагында
Елыйсы да елыйсы...
Чит җирләрдән алып кайта
Туган туфрак җылысы.

## ГАРӘП ГҮЗӘЛЕНӘ

Хисләремне аңлатырлык
Сүзләр белмим сезнең телдә.
Тоеп торам: карашлар да,
Йөрәкләр дә безнең бергә.

Уйларымда әллә ни юк,
Уйларымда түгел гөнаһ.
Сине эзләп килгәнмени...
Юкса мин бит сездә кунак.

Сезнең илдә чүл кояшы
Минем йөрәктән дә кызу.
Күңелемне сиңа бирсәм,
Сакларсыңмы, гарәп кызы?

Тыңлап тормассың шул мине,
Әҗнәбигә* монда юк сан.
Исләреңә мин төшәрмен,
Сахраларга ялгыз чыксаң.

Тирләп-пешеп шигырь язам –
Күңелемдә шигырь генә.
Хисләремне аңлатырлык
Сүзләр белмим сезнең телдә.

Барлык-барлык лөгатьтә дә
Мәхәббәтнең теле бер үк.
Сезнең илдә рөхсәт юк шул,
Алыр идем сине үбеп.

Сөюемне сүзләр белән
Аңлаталмам бугай бүген,
Җиргә ятыш шигырь язам,
Таянырга миндәр бирдең.

Рәхмәт! Шүкран җәзилән!

* Ә җ н ә б и *(гар.)* – чит ил кешесе.

## ТӘРӘЗӘҢ ТӨБЕНДӘ

Тәрәзәңдә синең өмет балкый,
Эх, беләсе иде серләрен!
Таң атканга кадәр көтеп ятам
Тәрәзәңдә утлар сүнгәнен.

Күңелемдә минем ни барлыгын
Белмисең шул әле, белмисең.
Бер күрәсем килә синең сынны,
Күтәр әле тәрәз өлгесен.

Таң ата ич, сүндер утларыңны,
Кояш кына көт син нибары.
Тәрәз өлгеләрең булсын әле
Хыялларым кадәр югары.

Ярый әле күләгәңне күрәм –
Бер юаныч ул да күңелгә.
Тәрәз төшләреңдә төн үткәрәм,
Пәрдәләрең ач та көл генә!

## САУБУЛЛАШУ

Хатирәләр төяп киткән чакта
(Хатирәләр ике «КамАЗ»лык!)
Истәлеккә диеп гарәп дустым
Бүләк иткән иде намазлык.

Намазлыкка сыеп беткән бугай
Бөтен дуслык, бөтен туганлык.
Без бу илдә туган җиребездә
Иркен сулар өчен тын алдык.

Гарәпме ул, башка милләттәнме,
Иң беренче туган, дус кеше!
Истәлеккә диеп гарәп дуска
Бүләк иттем казан сөлгесе.

## ARE YOU...?

*Америкада булып кайткан*
*дустым Рушанга*

Чит илләрдә йөргән чакта
Әйләнеп китсә башың,
Сораганнардыр ул синнән:
– Are you Russian?*

Диңгез арты гына түгел,
Океан артына аштың!
Иң хөр дәүләтнең берсендә
Are you Russian?

Син анда да ашамадың
Буш ботларының ашын.
Сәер караш тилмерткәндер:
«Are you Russian?»

Сораулары гел бертөрле,
Юкса дөнья безгә тар.
Сорасыннар иде лә ул:
– Are you Tatar?

---

* Are you Russian? (инг.) – Син русмы? Син русияле-ме?

## КАЗАН

*(Этюд)*

Башын күтәргән Кол Шәриф,
Бардыр бер тын аласы.
Болытларда –
Сөембикә-ханбикә манарасы.

Колонналары артыннан
Университет күлә.
Казансуга чумган кояш,
Кызу булганга күрә.

«Татнефть-арена» түзәрме
Казансудагы моңга?
Тиеннәргә чуарланган
Хан каберлеге туңа...

## ТУГАН АВЫЛЫМА

*Яңа Чәчкапка*

Сиңа кайттым әле, сагынылган.
Болыныңа чыктым кичкырын.
Мин яратам сине, туган ягым,
Бик яратам, диеп кычкырдым.

Кемдер, бәлки, ишеткәндер мине...
Миңа җитә, үзең ишетсәң.
Туган ягым, мин тирбәлеп ятам
Күккә элгән яшел бишектә.

Егылсам да, бер торырмын әле,
Бишегеңнән генә төшермә!
...Мин җиһанның күккә элә торган
Йолдызлары туар төшендә!

## СОРИЛЕ

Урман кебек яшел урамнарың
Юксындыра икән ят җирдә.
Балачакның гүзәл мизгелләре
Яңаралар бүген хәтердә:

Ап-ак йортлар...
Иркен урамнарың...
Таныйсыңмы, авыл, син мине?
Хатирәләремне эзләп киләм –
Бәхет кенә синдә, Сориле.

Хәзер дә мин балачактагыдай
Туфрагыңа сирәк килгәлим.
Сирәк булганга да бәхетләме
Минем синдә үткән көннәрем?

Офыккача киткән урамнарың,
Чәчәкләрең җиргә ямь өрә.
Урман кебек яшел урамында
Адашырмын сыман мәңгегә.

# КАЙТЫП КИЛӘМ СИҢА, МӘКТӘБЕМ!

*Яңа Чәчкап урта мәктәбенә*

Күңел тулы сүзләр... бүгенгәчә
Бер җылы сүз гүя әйтмәдем.
Балачакның сукмаклары буйлап
Кайтып киләм сиңа, мәктәбем!

Карлар ява тышта...
Сукмакны да
Башка карлар күптән күмгәннәр.
Күпме үттем моннан,
Әйтерсең лә
Тәүге тапкыр гына күргән мәл.

Балачакның сукмаклары буйлап
Кайтып киләм әле мин янә.
Күңел тулы сүзләр йөздән артык,
Күңел тулы хисләр мең парә.

Миллионер ук булган туган мәктәп!
(Хәерлегә булсын бу ырым.) –
Тоеп торам, мин киткәч тә монда
Меңәрләгән сукмак булырын.

Күңел тулы сүзләр...
Әлегәчә
Иң ихласын сиңа әйтмәдем.
Сукмакларың һәрчак җылы булсын,
Шаулап тор син, туган мәктәбем!

## МӘХӘББӘТНАМӘ

*(Газәл)*

Ай-кояш белән сине тиңләмим –
Хат кына язам сиңа төнлә мин.

Сүзләрем очсын синең тарафка,
Хисләрем белән һаман бергә мин.

Тор инде әйдә, гүзәл Хан кызы,
Күптәннән юк ла сине күргәнем.

Очрашыйк әле ватып вакытны,
Ул ачар безгә галәм серләрен.

Караңгы җиһан – кара тишемдәй –
Эченә кердем айлы төрбәнең.

Йоклама, торчы, гүзәл Хан кызы,
Күптәннән юк бит сине күргәнем.

## ТӨНЛӘ

Бу минутта төш күрергә
Тиеш мин.
Әмма үзем йокы белән
Килешмим.
Уйларымны төннәр белән
Бүлештем.

Төннәр йокласын! Аларга
Мин төшмен!

## ЭНДӘШМӘГЕЗ!..

*(Халәт)*

Зинһар, китегез ялгызым калдырып...
*Илдар Юзеев*

Эндәшмәгез миңа,
Мин башкача яшим:
Кулларымда – каләм,
Күзләремдә – яшен!

Эндәшмәгез миңа,
Уйларымда йөзәм.
Бу минутта бер дә
Файда юк шул сездән.

Эндәшмәгез миңа,
Мин башкача яшим.
Кулларымда – дөньям,
Йөрәгемдә – яшем.

Эндәшмәгез миңа,
Мин ялгызым хәзер.
Бу минутта мәңге
Тынарга да әзер.

Эндәш-ш-шмәгез!..

## БӨЕК ШАГЫЙРЬГӘ

*М.Ә-гә*

Бөек шагыйрь диләр аны...
Үзе сәер кеше ул.
Бәһасе дә шул ук аның,
Бәхетсезлеге дә шул.

Шагыйрьләрнең бөеклеген
Күреп-белеп булмый ул.
Сәер булып яши кеше –
Сәер булып тумый ул!

Тарлыгыннан чыга алган
Шагыйрь булган ул шуңа:
Бөеклеге дә шул аның,
Гадилеге дә шунда!

## ШАГЫЙРЬ КҮЗЛӘРЕ

Тыныч кына мин диңгезгә карыйм –
Минем өчен диңгез шашына.

*Зөлфәт*

Ул диңгезгә тыныч кына карый –
Читтән, бәлки, шулай күренә?!
Төшенергә кирәк әле безгә
Шагыйрь күзләренең серенә.

Уйчан караш, иркен сулыш анда,
Кайнар кояш – шуңа тере без.
Диңгез нинди булганлыгын әнә
Шагыйрь күзләреннән күрегез!

## 17 МАЙ, 2007

Бәлки, язмыш мине ишетер...

*Зөлфәт*

Матәм бүген. Кичә чәчәк аткан
Шомыртларга кадәр моң тулган.
Җирдән китеп күшләр откандыр ул,
Җирдән китеп күшләр оттырган.

Шагыйрь китә. Офыкларга китә.
Болытларга китә, күкләргә.
Ярсу яшен булып яшьнәр өчен,
Болытларны ярып күкрәргә.

Китә шагыйрь. Кайтмаска дип китә.
Ул тере дә түгел, үле дә.
Бу дөньяны моң-гөлләргә бизәп,
Үз язмышын салып иңенә.

Оттырмады шагыйрь, отмады да –
Язмыш аны бүген ишеткән.
...Офыкларны ярып дәшә берәү,
Аваз бирә берәү... Бишектән.

***

Җир йөзендә гомер сөргән
Күпме бөек шәхес.
Тик күбесен тоткын иткән
Ялган, гөнаһ, нәфес.

Җир йөзендә патшалар да,
Фәкыйрьләр дә кунак.
Кемгә – ерак, кемгә – якын
Нәфес, ялган, гөнаһ.

Тарих сәхифәләрендә
Кулъязмалар калган:
Дөнья җәннәт түгел,
Дөнья –
Гөнаһ, нәфес, ялган.

## Көрәш

Уян әйдә, дәвер ханы,
Сине бөтен гавам көтә.
Бер тыныш, бер давыллаиыш
Яшәү җирдә дәвам итә.

Тулпар атлар очып үтә
Күк шәрабы тамган җирдән.
Кар астында җәйрәп үсә
Корып беткән сары чирәм.

Уйлар яна, җырлар яна,
Томан кала сөременнән.
Яулар чабып ханнар кала...
Син югалма чирүеңнән.

Илдә җилләр хаким итә,
Сур тавышын гавам көтә.
Яшәү өчен җир йөзендә
Көрәш әле дәвам итә!

## БАСУ

Билгесезлек,
Буталчыклык.
Күпме чүпне җиребездән
Утап чыктык.

Оча гына
Күккә тузан.
Бу мин инде янә
Тынлык бозам.

Алдымда җир,
Минем ызан.
Карап торам
Җиремдәге манзараны.
Бусы кайсы хан заманы?

## ТОЗСЫЗ БОТКАДАН СОҢ...

Тоз булмаса, берни тәмле түгел:
Күмәчләр дә, ботка, бәлеш тә.
Сүзләреңә тоз сибәргә кирәк,
Тоз сибәргә мотлак рәвештә!

# ТУГАН КӨНЕҢ БЕЛӘН, ӘНИЕМ!

Җәннәт – аналарның аяк астында.

*Хәдис*

Туган көнең белән котлар өчен
Ни әйтсәм дә азрак ул, беләм.
Шигырь язып булмас,
Рәхмәтемне
Әйтеп бирә алмам сүз белән.

Син сүзләрдән мең мәртәбә өстен,
Күңелең дә сафрак ак кардан.
Кышкы иртәдә дә җылы җилләр
Генә исә сезнең яклардан.

Син үзең дә сүнмәс кояш, әни,
Үз җылыңны безгә бирәсең.
Юк, сайламас идем әни итеп
Синнән башкаларның берәрсен.

Туган көнең белән котлар өчен
Нинди теләк менә теләргә?
Күңелемдә булган изге хиснең
Барысын да төрдем гөлләргә.

Зәңгәр күктән ак чәчәкләр ява –
Чәчәк атканмыни шомыртлар.
Туган көнең көткән бер ел буе,
Гүзәллеген аның күреп кал!

Кыш уртасы әле.
Күзләреңә
Нурлар чәчеп яшел яз куна.
Чәчәкләргә күмеп юлларыңны
Җәннәт күрәм аяк астында.

## РИШВӘТ

Түрәләргә эшең төшеп бәйле калсаң,
Күзен йоммый акча сорар Корсак абзаң.
Авызыңны ачып басып каттың нишләп?
Куллары да биеп тора:
– Ришвәт!

Китер монда, торма әйдә ятсынып та,
Сиңа ярдәм кулы сузам бит чынлыкта.
Кулларында сыр-сыр калган ришвәт эзе
Һәм ялтырап: «Ришвәт!» – дияр күзе.

Теле белән ялап алыр кәгазьләрен.
Нишлисең бит, белә, димәк, акча тәмен
Һәм кулларын юар.
Кулны кул юа, ди.
Ничек юып бетерерсең каһәрләрен?

## ЙОКЛА, ЭНЕМ!

*Туганнан туган энем Илшатка*

Йокла, наным, йокла,
Күзләреңне йом да...
Күңелеңне генә япма син!
Мәхәббәттән дөрлә,
Күңелеңдә гел дә
Сагыш-моңнар гына ятмасын!

Йокла, энем, йокла,
Ни дисәң, юк-юкта
Төшләреңдә әле сабыйсың.
Өстеңә шәл ябам,
Зур үссәң дә, һаман
Абый булып килә карыйсым!

## ТАМЧЫ-ЯЗ

*(Цикл)*

**1**

Язларыма кадәр юллар ерак,
Офык ерьш, әйдә, барчы, бар.
Тәрәзәмә шакып уяталар,
Уяталар язгы тамчылар.

Тамчы-тамчы булып язлар килә,
Теләк телә тамган чагында.
Күңелләрдә язлар калган әле,
Язлар һаман минем янымда.

Ә офыклар ерак әле һаман,
Нәрсә эзлим шунда омтылып?
Олау-олау сорау йөрәгемдә
Янып китәр төсле ут булып.

Янып китәр төсле таңнар булып
Йөрәгемә тигән күзләрең.
Чәчәк аткан офык чикләреннән
Мин бит сине генә эзләдем.

Мин тик серләр генә эзләп йөрдем,
Серләр булып миңа калчы, кал.
Тәрәзәмне шакып уяттылар,
Уяттылар язгы тамчылар.

**2**

Яңа алган кара чалбарыма
Пычрак чәчеп үтте машина.
Түбәләрдән төшкән карлар сыман,
Уйлар килеп төште башыма.

Түбәләрдән тамган тамчы сыман,
Бимазалый минем йөрәкне.
Бер карасаң, юньле фикер дә юк,
Уй килүе генә кыйммәтле.

Бөтен нәрсә акча сыман бүген,
Кыйммәтле йә хаклы, бәяле.
Чорлар хөкеменә башын ия –
Язларның да беткән гаяре.

Яз килсә дә, үзенекен итә,
Үзсүзләнә бара кешеләр.
Күзләрендә яз чалымы сүнгән,
Ә үзләре хәйран эшлеләр.

Эшлик, ләкин гамьсезләнеп йөрмик,
Яз чаткысын кушыйк күңелгә.
...Яңа алып кигән чалбарымда
Табигыйлек шактый күренә...

3

Язгы күктә яңа ай калыккан,
Йолдызлары шулай дияләр.
Тәрәздәге яктылыкка карап,
Өй эчендә оча көяләр.

Күбәләкләр язны сизгән бугай,
Көя күбәләге булса да.
Сизеп торам: минем күңелне дә
Язлар алып килгән моң сара.

Сизеп торам: каным акмый бүген –
Йөрәгемнән тама тамчылар.
Уй-камчылар
Ярсып янып яткан
Йөрәгемне шактый камчылар.

Гаделсезлек, тагын гаделсезлек...
Юкса гадәт шундый бу илдә.
Ил шаукымы килеп кердемени
Язлар шытып яткан күңелгә.

Күңелемдә язлар шыта да бит,
Тамчы гына шакый тәрәзне.
Акыл өчен йөрәк җавап бирә –
Әнә шунда бөтен бәласе.

Берәү өчен берәү җавап бирми,
Кануннарда шулай язылган.
Кануннарны тотучылар булса,
Яз эзләмәс идем язымнан.

Язам әле бүген яз хакында,
Хакын хаклау аның тиештер.
...Язгы тамчы, әйдә, йөрәгемне
Язгы хисләр белән күрештер!

Яңа айның сары нуры тама,
Ай нурлары шулай дияләр,
Читлегеннән ирек таләп итә –
Тәрәзәгә кага көяләр...

**4**

Язгы җилләр, тәрәзәгә килеп,
Тамчыларга килеп бәрелде.
Өзгәлән бер.
Җаның өзгәләнер,
Кем дә аңламаса хәлеңне.

Бәлки, берәү мине аңлар диеп,
Язгы учакларда янасың.
Тоташтыру кирәк кайчагында
Офык белән офык арасын.

Күңел белән күңел араларын
Буташтыру гына кирәкми.
Сагышларга сусаганның җанын
Сагыш салыш язмыш сурәтли.

Сагышларга сусасаң да, бүген
Син баш тартма бер уч шатлыктан.
Күзләреңдә бәхет йөзәр тиздән,
Караңгыга кабар якты таң.

Бәлки, берәү мине аңлар диеп,
Сагышларга башың иясең.
Язгы җилләр хәбәр итеп тора
Тамчы-тамчы бәхет киләсен.

Көләлсәң – көл, елый алсаң – ела,
Елый-көлә ала язлар да.
...Тамчы-тамчы бәхет табар өчен,
Килеп кердем әле базарга.

Базарларда мин сорарга базам
Өлешемә тигән көмешне.
Базар түбәсеннән нидер күреп,
Тамчы-тамчы язлар көлеште.

Базар икътисады үзәгендә
Бәхетеңне кайдан табасың?
Бата-чума тоташтырып йөрим
Офык белән офык арасын.

# ШӘҺӘР ВАКЛЫКЛАРЫ

**1**

Агыла...
Агыла көннәрем,
Буа да буалмыйм вакытка.
Яшим мин җиһанда төннәрен
Минутлар ватып та.

Тагын бер көн килер, тойганда
Вакытның ватылган мизгелен.
Әзер мин каләмнән коярга
Хыялым тезгенен.

**2**

Яшьләремнең яшәрмәгән көне
Яшәлде.
Әллә мин: «Яратам!» – дип сиңа
Дәшәмме?

Сүзләремнең коелмаган комы
Чәчелде.
Ялгышып күргәнмен буялган
Чәчеңне.

**3**

Шәһәрнең шәрә бушлыгы
Таралган урамга.
Буранда адашып торсаң да,
Югалма!
Кулымда акбур бөртеген
Издем дә тараттым...
Сибелде син төйгән кара төн
Җиһанга!

ЯШЕЛ АГЫЙДЕЛ

# ЯШЕЛ АГЫЙДЕЛ

Мин – татар баласы!

Хәзерге минутта башкортларның бөек каһарманы Салават Юлаев янына барам. Салават Юлаев һәйкәле синең кебек: эндәшсәм, бер сүз дә әйтми, ләкин тыңлый! Тыңлый, ләкин ишетми.

Мине башкортлар кабул итмәячәк, татарлар янына да кире кайта алмыйм. Мин югалам!.. Менә чиксезлек бусагасын атлыйм. Ә ул озын... Мин йөгерәм. Янымда кешеләр бара, әмма алар һәйкәлдән дә җансызрак күренәләр. Кешеләр – җансыз!!! Хәтта син дә!!! Ә, юк, син җансыз түгел. Синең җаныңны күрмәвем синең җаның эчендә булуымнан икән.

Мин һәйкәл каршындагы ташка утырып нәсер язам. Кешеләр сәерсенеп карап китәләр. Әйе, мин – иҗат кешесе. Ә иҗат кешесе сәер булырга тиеш! Бу хакта «Иҗат кодексы»нда язылган. Бу кодекс күп кенә кануннарга, хәтта бөек «Йөрәк конституциясе»нә дә каршы килә. Мәхәббәт кебек.

Мине бу юлга мәхәббәт чыгарды да инде. Ә хәзер кая барырга белмичә йөрим. Мин – кыйбласын югалткан гыйбадәт кылучы сыман. Әйе, сыман гына, чөнки синең булуың миңа ниндидер чаткы, кечкенә генә маяк ул. Яшел маяк!

Кояш байый... Офыклар – алтынсу... Алар да барыбер Агыйдел буендагы каеннарга кагылып яшел төскә керәчәкләр. Күктә күптәнге яшел ай.

Мин китәм!

Мин – татар баласы!

Шулай да һәйкәл куймаслык, әмма Салават Юлаевтан да олырак батырлык эшләргә әзер!!!

## ЯЗ ГҮЗӘЛЕНӘ

Гүзәллеккә карап торган өчен,
Хак түләргә миндә юк алтын.
Аңлый алмыйм, ләкин тоеп торам –
Күзләреңдә нидер югалттым.

Гүзәллектә эреп югалырмын,
«Сөям!» диеп бер сүз дәш кенә.
Иртә язның тәүге чыгы сыман,
Күзләреңдә балкый яшь кенә.

Гүзәллегең, серле күзләреңнең
Бәһасенә мең җыр аз сыман.
Өмет кочагында калдыр мине,
Безне таныштырган яз сыман.

## КИРӘК МИҢА...

Бер сүз генә кирәк миңа,
Бер сүз генә.
Бу дөньяда яшәп булмый
Гөлсез генә.
Кара күзләр, уйларымда
Гел сез генә.

Сез сөйләшәсез... Иягез
Сүзсез менә!

## ПАРКТА

Һәркемнең дә монда үз тормышы:
Кемдер бала җитәкләгән, кемдер этен,
Кайсыныңдыр авызыннан җыр-моң чыга,
Кайсыныңдыр авызыннан чыга төтен.

Һәркемнең дә монда үз язмышы:
Берәүләре уйчан, моңсу, берәү көлә,
Берәүләре чәркәләргә хәмер сала,
Берәүләре атлап йөри гамьсез генә.

Һәркемнең дә монда үз дөньясы:
Ишекләре кайсы ябык, кайсы ачык.
...Уртак язмыш эзләп берәү юлдан килә –
Бәгыремә массаж ясый, шак-шок басып.

## ТАБЫШ

*(Диптих)*

**1**

Сөйләшмәдек.
Ләкин тойдым бүген
Якынлыгын синең күңелнең.
Күзләреңә тамып
Әкрен генә
Якты очкын булып терелдем.

Сөйләшмәдек.
Күз карашы белән
Бер-беребезне генә күзләдек.

Беләсеңме?
Үз дөньямны таптым
Гомерем буе серен эзләрлек.

## 2

Ярсу идең бүген –
Тыңламадың,
Тик ишеттең минем серемне.
Әле кичә генә чәчәк аткан
Шомыртларга кадәр сөенде.

Бөтен җиһан балкып киткән булды,
Күзләремдә кояш чагылды.
...Бер син генә күреп калдың минем
Иң бәхетле булган чагымны.

***

Ак каеннан эскәмия
Утыргычы.

Күзләреңдә очкын түгел –
Ут оргычы.

Син ул мине мәхәббәткә
Ыргытучы.

Кулларымда каләм түгел –
Офык очы.

## СИРИНЛЕ ЧЕЛТӘР

Сирин чәчкәләре хуш ис чәчә...
Сирин чәчкәләрен күреп кал!
Болытлар да качкан,
Көн дә аяз,
Ә чәчкәләр шундый боеклар.

Нидер дәшә сыман,
Нидер әйтә –
Тавышларын гына ишетмим.
Мин хәтерлим әле сирин-чәчкә
Челтәр иде минем бишекнең.

Сирин чәчкәләрен тәү күргәндә
Инде тәпи баскан булганмын.
Бүген менә сириннәргә карап
Челтәрләрен күрәм дөньямның.

Челтәрләрен үрәм язмышымның
Сириннәргә тулган галәмнән.
...Җырларым да минем шул ук төстә –
Сирин кара ага каләмнән!

## СИРИНЛЕ МӘХӘББӘТ

Сириннәрне бәйләмнәргә җыеп
Әле сиңа бүләк итмәдем.
Үпкәлисең инде нигәдер син...
Беләм инде гөлләр көткәнең.

Бүләк итеп көтәсеңдер, бәлки,
Сириннәргә төргән сүземне.
Ачылмаган серләр калсын җирдә,
Син беразга гына түз инде.

Язлар белән сөю килгән мәл бу –
Чәчәк аткан мәле сириннең.
Чәчәк аткан сирин чәчкәсеннән
Сөйкемлерәк үзең син бүген.

Сириннәргә төргән сөюемне
Бәйләм итеп сиңа биралмам.
Син күрерсең минем хисләремне
Сирин чәчәк аткан урамнан.

## КАНАТЫҢНЫ САЛДЫҢ УЧЫМА*

Фәрештәдә канат була, диләр...
Болытлармы синең канатың?
Әкрен генә шәфәкъ яктысында
Җир-күкләргә иңә кара төн.

Төн яктысы җиргә таралганда,
Офыкларга офык кушыла.
Күкләр буйлап очып әйләндең дә
Канатыңны салдың учыма.

Канатыңны сиңа кире бирәм,
Бүләк итәм күкләр дәрьясын.
Җир-күкләрне тоташ бәхеткә төр,
Күзләреңдә генә калмасын!

Җир-күкләргә аклык кына юра –
Актан гына торсын бу галәм!
Каурыйларың очсын кайнар җилгә –
Сагышларын үзем күтәрәм!

* Илшат Сәлахов көе.

Син – фәрештә, бар күкләрне иңләп,
Болытларны иңләп оч кына!
...Күк гөмбәзен очып әйләндең дә
Канатыңны салдың учыма.

## ҖАННАРЫБЫЗ БЕРТУГАН

Син мине ошатасың да,
Ошатмыйсың да сыман,
Сине тоям, әйтерсең лә
Җаннарыбыз бертуган.

Ә мин тоеп-сизеп торам:
Җаннарыбыз бер безнең.
Шуңа серле йөрәгеңнән
Мәхәббәт-сөю эзлим.

Шуңа серле карашыңның
Һәр бөртек нурын тоям.
Син мине күзәтәсең дә,
Күзәтмисең дә сыман.

Минем гашыйк күзләремә
Багасың сынау белән.
Сиңа карыйм күңелемдә
Меңләгән сорау белән.

Куралмасаң да син мине,
Җаннарыбыз бертуган.
Ә үзең яратасың да,
Яратмыйсың да сыман.

## КҮПЛӘР СИҢА ГАШЫЙКТЫР

Хушлашабыз... Чын күңелдән теләк:
Ярларыңнан һаман ташып тор!
Берни булмас диеп сүнә күрмә,
Күп егетләр сиңа гашыйктыр.

Бу тормышның кырыс чынлыгыннан
Хыялларың белән качып тор.
Мин киткәннән дөнья җимерелми,
Күп егетләр сиңа гашыйктыр.

Язмышыңнан гына кача күрмә,
Һәр иртәне ишек ачып тор.
Яратып та өлгермәдең бугай...
Күп егетләр сиңа гашыйктыр.

Хаталарың синең төзәтерлек,
Хаталандым мин дә, ачык бел!
Миндәй яраталмас сине кем дә,
Бәлки күпләр сиңа гашыйктыр.

## СОРА ӘЛЕ!..

Сора әле, сора күңелеңнән –
Кемне йөртә иң-иң түрендә.
Бакчаларда әгәр гөлләр сулса,
Күңелеңдә сары сагыш булса,
Гөлләрең бар тәрәз төбендә.

Сора әле, сора йөрәгеңнән –
Кемнәр өчен диеп җилкенә.
Йолдызларың әгәр ерак булса,

Күгендәге аең урак булса,
Син борчылма, безне җир күрә.

Сора әле, сора күңелеңнән –
Кемнәр өчен диеп ул яна.
Карашларым әгәр ерак булса,
Күңелеңә соңгы сагыш тулса,
Онытকандыр диеп уйлама.

## ТАҢ ТУГАНДА

Мәхәббәтме, әллә саташумы –
Йөрәк әрни минем: «У-у, янам!»
Өметләрне кочып йоклап китәм,
Таң туганда кинәт уянам.

Яратумы, әллә талпынумы?
Яра тулы күңел – ул сүнә.
Мин һаман да күбрәк кереп барам
Кара төнле төшләр эченә.

Сөенүме, әллә сөрелүме
Төш иленә фани тормыштан.
Тәрәз төбемдәге гөлләрем дә
Таң чыклары белән тулышкан.

Мәхәббәтме, әллә саташумы?
Кемнәр әйтер: бу – чын, бу – ялган.
Хыялларны кочып йоклап китәм,
Шабыр тиргә батып уянам!..

## КАГЫЛ ӘЙДӘ, КАГЫЛ ҖАНЫМА!

Бөдрә чәчләреңне тарап үр дә
Күзләремә кара сак кына.
Минем күңел күптән сынган инде,
Кагыл әйдә, кагыл җаныма...

Төннәре дә, җилләре дә иркә,
Чәчләреңә килеп сарыла.
Чәчләреңне салкын җилләр тарый...
Кагыл әйдә, кагыл җаныма.

Синең хакта беркемгә дә әйтмәм,
Серне чишмәм сөйгән ярыма.
Син борчылма, горур үтеп кит тә
Кагыл әйдә, кагыл җаныма.

Артка юл юк, диләр, бар икән шул,
Йөрәк һаман сине сагына.
Үзәк өзгеч карашыңны ташлап,
Кагыл әйдә, кагыл җаныма!

## АКЛАНЫРГА ТИЕШ

Үзеңне дә өзелеп сөйгән чакта
Яратуың нигә белгертмәдең?
Нигә кабат яннарыңа килдем,
Акланмаслык булгач өметләрең?

Йолдыз саный-саный йөрдем кичен,
Үзең генә никтер төн көтмәдең.
Нигә алсу алма булып пештең,
Акланмаслык булгач өметләрем?

Алмаларның иң-иң кызылларын
Өзеп алма диеп үгетләдең.
Нигә биеккәрәк омтылдым соң,
Акланмаслык булгач өметләрең?

Мең ялгышып кире сиңа кайттым –
Күңелемнән генә син китмәдең.
Нигә буйсынырга язмышларга,
Акланмаслык булгач өметләрем?

Карашларың җанны өтеп алды,
Әйтеп бирми түзмәм күңелдәген:
Акланырга тиеш өметләрең,
Акланырга тиеш өметләрем!

## САФ КЫЗГА

Бу дөньяда җиңел түгелдер ул
Ала карга булып яшәве.
Күзләреңнән ташый мәхәббәтнең
Саф тамчыдай керсез яшьләре.

Син җир тузанына буялмаган,
Төшкәнсеңдер, сылу, күкләрдән.
Күпме яшьтәшләрең зөфаф кичен
Никахына кадәр үткәргән.

Бу гавәмдә җиңел түгел ансы
Ала карга булып яшәве.
Булса иде синдәй барысы да
Бу гасырның яңа яшьләре!

## ЯНЫҢА БАРАМ ТАГЫН

Әллә нурмы, әллә моңмы...
Күңелгә нидер тулган.
Уйларымда синең сурәт,
Юлымда – күксел томан.

Мин сине иң тәүге тапкыр
Ятарып калалмадым.
Күксел томаннарны ерып,
Янына барам тагын.

Шытып чыгармы хисләрем –
Күңелем тулы бөре.
Үткәннәргә юл юк, диләр,
Кайтып була ул кире.

Син миңа шундый якын күк,
Күңелләр гүя туган.
Болытлар көлә кушылып,
Юлымда – күксел томан.

Сине тәүге күргән чакта
Яратып калалмадым.
Хисләремә түзә алмый
Янына барам тагын.

# ТУГАН КӨНЕҢ БЕЛӘН КОТЛАР ӨЧЕН...

Табын әзерлисең...
Талгын җилдә
Җилфер-җилфер килә чәчләрең.
Туган көнең белән котлар өчен,
Шушы көнне көтеп яшәдем.

Табыныңның бөтен татлылыгы,
Яктылыгы синең кулдан ул.
Кулларыңа кергән әфлисунның
Киселәсе килеп торгандыр.

Гомере дә әрәм түгел аның
Учыңдагы күпме наз өчен.
Сеңдереп кал әле шомыртларның
Хуш исләре тулган яз исен.

Табын әзерлисең моңсу гына...
Белмисең шул минем күңелне.
Кочак-кочак йолдыз кочагымда,
Син шуларны гына күр инде.

Галәмдәге йолдыз давылыннан
Җемелдәшеп ала күзләрең.
Табыныңа куяр җимеш булам,
Өстәлеңә куйчы, гүзәлем!

# ТУЙДА

Тәүге күрмим, ләкин сиңа
Гашыйк булдым туйда күреп.
Хисләремне көйгә салам,
Агыйдел дә тыңлар кебек.

Күңелемдә ташкан хискә
Йөрәк ничек түзәр бүген?!
Йолдызлары бии күкнең,
Һушны ала гүзәллегең.

Әй биибез икәүләшеп,
Без кунаклар гына туйда.
Әйтә алмыйм каршы килеп:
Күкрәгемә башың куйма!

Беләсеңме, синең белән
Бүген минем туем кебек.
Минем өчен иң зур бәхет
Синең җылы куен кебек.

Нидер дәшәм, сөйлим сиңа,
Ансы артык мөһим түгел.
Ап-ак болытларда йөзә
Синең күңел, минем күңел.

Эндәшмик без, сөйләшсеннәр
Икебезнең дәртле йөрәк.
Өйләнешкән парлардан да
Без бу кичтә бәхетлерәк!

# ЮКӘ ИСЕ *

*(Җыр)*

Күзләреңне яшерәсең,
Нигә соң үпкәләдең?
Синең өчен чәчәк ата
Урамда юкәләрем.
Юкә чәчәкләре генә
Җаныма дәва икән.
Юкәләрнең гүзәллеген
Син дә күр әле, иркәм!

К у ш ы м т а:

Юкәнең татлы исеннән
Әйләнсен әле башым.
Сине генә сөям, җаным,
Яшел күз, кара кашым.
Сәбәпсез үпкәләсәң дә,
Ошыйсың миңа һаман.
Карашларың ялкынында,
Сөю утында янам.

Нигә, иркәм, моңсуланып
Карыйсың күзләремә?
Шул үпкәләүләрең белән
Үттең бит үзәгемә.
Керсез сөюемә шаһит
Ирекле төнге урам.
Үпкәләүле карашыңнан
Күзем алалмый торам.

К у ш ы м т а.

---

* Фоат Әбүбәкеров көе.

## КАЯ ЮГАЛДЫҢ СИН, ЗИЛӘ? *

*(Җыр)*

Күзләреңдә әллә яшьләрме,
Бер җылы сүз миңа дәш әле!
Кирәк түгел көньяк кояшы –
Хисләремне кая куясы?

К у ш ы м т а:

Кая югалдың соң син, Зилә? –
Күңелемдә бүген зилзилә.
Күңелемдә минем син генә, син генә,
Кая югалдың соң син, Зилә?

Карыйсың да, йөрәк җилкенә,
Чәчләреңне назлый җил генә.
Бер кагылыйм әле үзеңә,
Йөрәк ярсый, үзәк өзелә.

К у ш ы м т а.

Төшеналмыйм һаман серенә:
Ник күңелдә һаман син генә?!
Гашыйк булдым синең үзеңә.
Кая югалдың соң син, Зилә?

К у ш ы м т а.

---

* Илнар Сөләйманов көе.

## СҮРЕЛМӘ, КОЯШКАЕМ!

Кичер мине, ялгыш сине
Сагышларга салганмын.
Синең коңгырт күзләреңә,
Сизеп торам, сарган моң.

Моңсулык күмеп китмәсен
Кашыңның кыйгачкаен.
Минем күңелдә син генә,
Сүрелмә, кояшкаем!

## ӨМЕТ ЙОЛДЫЗЫ

Күңелеңә илтер юлга чыктым,
Күңелеңә кадәр юл озын.
Алларымда күпме сукмак ята,
Күкләремдә өмет йолдызым.

Күкрәгемдә – йөрәк.
Типсен әйдә,
Дөп-дөп итү аңа килешә.
Күкләр күзен йомган.
Йолдызлары
Күзләремә карап көлешә.

Тик бер генә йолдыз бер сүз дәшми,
Шунсы микән өмет йолдызым?
...Мин бит сине төнлә эзләп таптым –
Төшләремдә күрәм көнозын!

# СӘЛАМ БЕЛӘН

Ераклардан сиңа бер хат язам –
Хатым тулы кайнар теләкләр.
Хатка гына сыеп бетәр микән
Йодрык кадәр безнең йөрәкләр?

Хатка гына сыеп бетәр микән
Галәм тулы әйтер сүзләрем?
Юкка гына һәрбер сөю хисен
Энҗе итеп биткә тезмәдем.

Юкка гына диеп уйлыйсыңмы
Бәйләм-бәйләм шигырь язганым,
Беләсеңме икән синең өчен
Күңелемдә күпме наз барын?

Күзләреңә очкын гына кунсын,
Канатланып очсын бу хатым.
Ераклардан сиңа бер хат язам,
Сәлам белән синең Рифатың!

## ГАРӘП МӘДӘРРИСӘСЕ

*(Шаяру)*

Ярты сүзең аңлыйм,
Ә яртысын
Күзләреңнән укыйм.
Сиңа карыйм да мин, күзләремнән
Кача бөтен йокым.

Бөтен вөҗүдем дә шашып гашыйк,
Күңел генә түзем.
Син дөньяда тәүге шәркый гүзәл,
Кияүдә шул үзең.

## ИРЕНЕНДӘГЕ МИҢЕҢ

*(Шаяру)*

Гади генә бер көн иде
Әлегә кадәр бүген.
Күреп алдым син гүзәлнең
Иренендәге миңен.

Бар дөньяны нурга төреп,
Мине сихерләгәнсең,
Яңадан үз акылыма
Кире китермәгәнсең.

Шул миңеңә үрелеп бер
Үбәсем килгән иде.
Миңеңне якыннанрак
Күрәсем килгән иде.

Берүзең дип торам тагын,
Егетең булган синең.
...Иреннәремне тешләтте
Иренеңдәге миңең.

## НИШЛИСЕҢ АНДА?

*(Шаяру)*

Күзне ачсам – син өстә,
Күзне йомсам – син төштә...

Нәрсә инде бу дисәм –
Бик якын икән түшәм.

Ә түшәмдә син үзең
Әллә ниләр сөйлисең.

Күзне йомып качалмыйм,
Күзне йомсам, ачалмыйм.

Ә син һаман да өстә.
Өн түгел лә бу – төш лә!

Белмим инде, буталдым,
Әллә нинди бу вагон.

# УФА ТӨНЕ

Уфа урамында караңгы төн,
Мин йөгерәм... Белмим үзем дә,
Әллә кая таба чабам?
Әнә
Юл буена төннәр тезелә.

Караңгылык мине өркеталмый,
Өркеталмый бозлы карашың.
Әйдә әле, шушы салкын күзләр
Мең мәртәбә миңа карасын!

Йөрәгемнең ярсу учаклары
Эретерлек бозлы тауны да.
Әйдә инде, минем юлларыма
Караңгылык булып яу гына!

Уфа. Караңгы төн. Керәп барам
Кара күзләреңнең эченә.
Сизеп торам: бу мизгелдә күктә
Меңәрләгән таулар ишелә.

Уфа төне озатып кала мине
Төнге серле күкләр катына.
Тынып кала кала.
Бу мизгелдә
Зөһрә йолдыз үзе атыла.

Зөһрә йолдыз, күктән очкан чакта,
Атылсачы безнең уңайга?
...Синең йөрәгеңә өметләнеп
Керәп барам төнге Уфага.

## КАБЫЗ!

Если есть в кармане пачка сигарет...

*Виктор Цой*

Күзләр килә тышта,
Явар җиргә кар-боз.
Тәмәкеңне ташла,
Ә чакмаңны кабыз!

Күзләр килсә килсен,
Яңгыр яусын әйдә!
Юкса күптән инде
Иягәштек җәйгә.

Яфрак яусын җиргә,
Алар уттай сары.
Тәмәкеңә төр дә
Тартып кара аны!

Бәгырьләргә тия
Яфрак исе, сулыш...
Кайдадыр тынычлык,
Ә кайдадыр – сугыш.

Хисләр килә тышта –
Бәхет белән сагыш.
Күзләреңә ут төрт –
Йөрәгеңне кабыз!

# ЕГЕРМЕНЧЕ ТАҢ

Ямьле җәйнең бер иртәсе,
Калды бөтен як тыныш.
Кояш түгел, тамды җиргә
Күзләреңнән яктылык.

Болындагы бар гөлләрнең
Чыкка күмелде күзе.
Салават күпере бугай
Карашларыңның эзе.

Иң бәхетле мизгелләрең,
Иң бәхетле көннәрең.
Офыкларга кадәр җитә
Елмаюың, көлгәнең.

Офыкларны иңләп үтә
Хыялларың, өметең.
Син бит бүген күкләр белән,
Җирләр белән бербөтен.

Туган көнең бүген, сиңа
Нәкъ егерме яшь кенә.
Янәшәңдә бәхетең бар –
Үз яныңа дәш кенә.

## ДИҢГЕЗДӘ

Диңгез буе.
Күңел тулы моң бар,
Вакыт зая уза... Ник әрәм?
Күзләреңә сөеп багар мәлдә
Яр буенда вакыт үткәрәм.

Ә күзләрең назлырак та иде...
Диңгез генә шаулый күңелдә.
Ничек итеп шушы комлы ярны
Карашларың белән күмәргә?

Карашларың сагындыра сыман,
Диңгез кебек моңлы мин үзем.
Диңгез дулкыннары кочагында
Басып торам икән берүзем.

## КҮҢЕЛ БӨРТЕКЛӘРЕ – 2

Төшеп китте күңел
Җир өстенә.
Ватыкларын җыям,
Көлләрен...
Таныш түгел илдән
Туган якка
Очып китте синсез көннәрем.

Кояш бата...
Баесын ла әйдә,
Мин оныттым инде барысын.
Күңел бөртекләрен күккә сибәм.
Учларыңа җыеп барырсың!

## ӨЗЕЛМӘСЕН АЛСУ ИРТӘЛӘР *

Тәрәз төпләрендә гөлләр үсә,
Бит очларың төсле ал алар.
Төннәремнең йолдызлары сүнде,
Өзелмәсен генә ал таңнар.

Тәрәз төпләрендә үскән гөлләр
Синең кебек шундый иркәләр.
Өметләрем офыкларга аша,
Өзелмәсен алсу иртәләр.

Кояшыңның нуры җитми мәллә,
Башын игән моңсу яраннар.
Сөюебез бер өзелде бугай,
Өзелмәсен әле аралар.

Тәрәзәдән яулык болгап кала
Гамьсез генә үткән көннәрем.
Өметләрем гөрләп чәчәк ата,
Боекмагыз әле, гөлләрем!

## ТАШ БӘГЫРЬ

*(Халәт)*

Таш бәгырьгә әверелеп барам...
Бәгырьләрне кискән кайчы сына.
Бу дөньяда күпме сукмаклар бар,
Барып егылырга кайсысына?

---

* Илнар Сөләйманов көе.

Таш бәгырьгә әверелеп барам,
Яраларның тоймыйм әрнүен дә.
Аңлый алмыйм, ничек саклангандыр соң,
Мәхәббәтем калган әле миндә.

Хатирәләр калган...
Чынбарлык бер
Йомшартачак әле бәгыремне.
Ишет, җиһан!..
Синең бер гашыйгың
Гашыйк булмас җанга әверелде.

## КАЛДЫ МИКӘН?..

Бәхет чолгап алса бөтен яктан,
Гел җырлыйсы килә, көләсе.
Ирексездән уйлап куям шулчак,
Калды микән яшәү күәсе?

Өметсезлек чолгап ала калса,
Нишлисең бит, безгә күрәсе.
Хыялларның кыйшылчыкларында
Калды микән яшәү күәсе?

Кайчагында горур буласың ул,
Дәрәҗәле кеше, янәсе.
Даннарыңның ташы арасында
Бармы икән яшәү күәсе?

Алда әле киң офыклар ята,
Язмышларны меңгә бүләсе.
Хыял белән чынлык арасында
Калган икән яшәү күәсе.

***

Күңелеңдә кайнар учак булсын,
Кочаласың икән, коч барын!
Көзге чаганнарга тиеп үт син,
Яфраклары – минем учларым.

Әкрен генә килеп барасың син
Сукмак буйлап, аяк очында.
Җантибешем саны мең кат арта –
Адымнарың тоям учымда.

## КӨЗГЕ КҮБӘЛӘКЛӘР

Яфраклар егылып төшми,
Яфраклар оча гына.
Ашкына алар җирдәге
Сөйгәне кочагына.

Сагына алар сөйгәнен,
Саргайган алар шуңа.
Ял итеп алалар менеп
Болытлар арасына.

Күбәләк булып очсыннар,
Җилләре шаулап иссен!
Яфракларда – сагышларым,
Сөюем синең өчен!

## КӨЗ БҮЛӘГЕ

Икебезне таныштыру өчен
Бүләк итте язмыш көз мәлен.
Сары көзнең сары яңгырларын
Ера-ера сине эзләдем.

Икебезне таныштыру өчен
Бүләк итте язмыш үз мәлен.
Беркайчан да юкса болыннарда
Көзге чәчәкләрне өзмәдем.

Салкын яңгырларда чәчәк аткан
Ул гөлләрне син дә өз, әйдә!
Бүләк итеп тапшырырсың аны
Безне таныштырган көзләргә.

Күңелләрдә сөю канатлана,
Әйтерсең лә бүген яз тышта.
Сине алып килгән яңгыр өчен
Рәхмәт әйтеп йөрим язмышка!

## МИЛӘШ ТӘМЕ

Күңлеңдә ташыган хисләрне
Белмәсен беркем дә, белмәсен!
Хисләрең дисбесен сүткәндәй,
Тәлгәшләп коела миләшең...

Тәрәзәң төбендә ут яна,
Пәрдәңне нигә дип ачмыйсың?
Син бүген тәүге кат дөньяда
Тойгансың гыйшыкның ачысын.

Ә гыйшык татлы да, ачы да –
Миләшнең бар тәмен сеңдергән.
Күзләрең пышылдый каршыда,
Мәхәббәт көтәсең син миннән.

Мәхәббәт көтәсең... Минем дә
Хисләрем төренгән җаныма.
Миләшләр тәрәзгә төбәлә,
Карашың йөрәкне яндыра.

Карашың чаткыга уралган,
Күңелең түрендә мең яшен.
Әчкелтем тәмнәрен миләшнең
Белмәсен беркем дә, белмәсен!

## ВИДАГЪ

*(Идиллия)*

Кинәт кенә туктап калган дөнья...
Кошлар ишетелми. Инеш – тын.
Кыш-сылукай килә салмак атлап,
Иңнәренә салган көмеш тун.

Кыш-сылукай килә ак сукмактан,
Бураннары акбүз ат сыман.
Юл читенә гөлчәчәкләр тезгән,
Сөйгән ярлар язган хат сыман.

Тынып калган дөнья куенында
Торып калган икән кар-буран.
...Кыш-сылукай өчен түгел, сиңа
Йөрәк-йөрәк сөю калдырам.

## МИЛӘШЕМ *

*(Җыр)*

Ачы була диләр миләшне,
Ә мин менә туймыйм ачысын.
Кызыл миләш төсле сөюем,
Серен, бәлки, син дә ачарсың.

К у ш ы м т а:

Сине уйлый-уйлый мин яшим –
Күңелемдә яшьни мең яшен!
Син сөйкемлем минем, гүзәлем,
Татлылардан татлы миләшем!

Иренеңдә тәме калса да,
Сакла аны, сакла, сөйгәнем.
Ул миләшнең баллы чакларын
Белик бары икәү: син дә мин.

К у ш ы м т а.

Миләшләргә кунган кошларны
Көнләштерик әле икәү без.
Сөюебез тулган җимешне
Кошларга да бүләк итәрбез!

К у ш ы м т а.

* Илнар Сөләйманов көе.

## МӘХӘББӘТ КАРШЫНДА

Унсигез яшь тә юк әле сиңа –
Офыкларың тулы йөз галәм.
Синең мәхәббәтең яктысында
Мин яшәрәм менә, үзгәрәм.

Тутыгып ук барган йөрәк иде,
Йөзгә чыккан җитди кыяфәт.
Ә шулай да тоймый дөнья чиген,
Мәхәббәттә яшәү, әй рәхәт!

Син куйгансың миңа канат-күңел.
Күкләреңнән нурдай яу гына.
Җансызларга берни кирәк түгел,
Сөю кирәк икән җанлыга.

Бәхетеңнән елый калсаң – ела,
Бәгырьсезгә генә яшь әрәм!
Сиңа, ахры, ныграк гашыйк булам,
Ике елга кинәт яшәрәм.

Яңгырлары әйдә яусын гына,
Язсын җиргә җырлар көз-каләм.
Йөз галәмнән торган офыкларга –
Мәхәббәткә килеп тезләнәм.

***

Сагыныр мине бу йортлар,
Сагыныр ишегалды.
Синең йөрәгең янында
Йөрәгем төшеп калды.

## САНДУГАЧ БЕЛӘН ХУШЛАШУ

Яфракларын койган каенкайны
Юатырга бер сүз дәш әле.
Ул яшертен генә сиңа гашыйк,
Күзләрендә аның яшь әле.

Нигә эндәшмисең, сандугачкай,
Хушлашканда сүзсез каласың.
Син бит әле башка илләрдә дә
Талга кунып сайрый аласың!

## ХУШЛАШЫРГА ВАКЫТ

Хушлашырга вакыт безгә
Танышмаган да килеш.
Синең дә бар, минем дә бар
Өлешкә тигән көмеш.

Хушлашырга кирәк безгә,
Йөрәкне әрнетмичә.
Бу турыда белми идек,
Шат идек әле кичә.

Хушлашырга кирәк безгә,
Бөреле сөю белән.
Болай да бер йөрәгемне
Ике өлешкә бүләм.

Хушлашырга вакыт безгә,
Килми шул газаплыйсым.
Безнең күңелләребез дә
Сөюдән азатмы соң?

Хушлашырга кирәк...
Ә бу –
Сөю иленә кереш.
Саубуллашып карыйк әле
Танышмаган да килеш.

## ЯРАТЫП ТОР...

Үпкәләмә, кичерә күр берүк,
Күңелеңә салсам мең яра.
Минем күңел, юк, синеке түгел,
Ләкин син дип әрни, моңлана.

Минем күңел, юк, синеке түгел,
Кичерә күр... Хәер, кичермә.
Чәчәк атарга ук әзер юкса
Күңел болынында хисем дә.

Чәчәк атарга ук әзер сөю,
Юк, юл куймыйм бүген мин аңа!
Мәхәббәткә ярты адым калды –
Күңелеңә салам мең яра...

Яратырга әзер инде үзем
Иртәсен дә, көндез, кичен дә.
Бер кайтырмын гафу сорап, ә син
Яратып тор минем өчен дә.

## КИЧЕРСӘМ

Гашыйк булу – бәхет дигән идем...
Бүген инде күпме аһ ордым.
Күңелемә мин хыянәт кылдым
Уйлап бетермичә ахырын.

Күңелемә мең хыянәт кылдым,
Авыр миңа үзем алдында,
Үпкәләгән, әмма чынлап гашыйк
Алсуланган йөзең алдында.

Гашыйк булу кояш көтү бугай,
Үзем генә шуны аңламыйм.
...Белеп торам, тоеп торам, иркәм,
Синең өчен атар таң барын.

Үпкәлә син, тик үпкәлә генә,
Иртән китеп кабат кич килсәм.
Яннарыңа кире барыр идем,
Үз-үземне әгәр кичерсәм.

## ЕЛАДЫҢ

*(Триптих)*

**1**

Еладың төн буе... Еладың...
Мендәрең... Ул – шаһит, ул белә.
Син бары бер хата кылгансың,
Гафу да сорадың бер генә.

Еладың төн буе... Йолдызлар
Атылды тәрәзәң төбеннән.
Юк, синең мендәргә яшь түгел,
Иң ихлас хисләрең түгелгән.

**2**

Еладың төн буе, нигәдер
Йокыга китмәде күзләрең.
Ә үзең тын гына бер мәлгә
Изрәдең, изрәдең, изрәдең.

Еладың төн буе, еладың...
Йокыга китмәде күзләрең.
Бу дөнья чынлыгы эченнән
Хыялың хәятын эзләдең.

**3**

Еладың төн буе... Ай гына
Белде дип ышаныш уйлыйсың.
Мең төрле фикер йөрт, шулай да
Уйларың тик нурлы уй булсын!

Еладың төн буе... иртәгә
Ачарсың дөньяның сер-ямен!
Елама, тын гына йокла син,
Мин сине кичерәм, сөйгәнем!

## ОНЫТМАДЫМ

Син еракта миннән.
Искән җилдән
Килер диясеңдер хәбәр-хатым...
Күңелемдә йөртәм сагышыңны –
Онытмадым сине, онытмадым.

Ерак араларны
Якын итеп
Барыш җитәр күңлем тулы ялкын.
Сагышларың булыш кышлар килде.
Онытмадым сине, онытмадым.

Хат-хәбәрләр сиңа
Юллап тормам,
Бер килермен – күңел-ара якын.

Кышларыңны язлар үбеп алыр,
Онытмадым сине, онытмадым!

Сагышларга
Аклык теләп кенә
Коеп йөри бугай болыт карын.
Йөрәгемдә йөргән мәхәббәтне
Онытмадым, җаным, онытмадым!

## КҮЗЛӘРЕҢӘ БАГАМ

Бу дөньядан һәркем бер ямь эзли,
Күрә җирдә һәркем үз ямен.
Күзалдымда сылу сының тора,
Карашларың тора, күзләрең...

Һәркемгә бер маяк кирәк җирдә,
Үз янына дәшкән якты нур.
Төннәр гизәм, әгәр сине күрсәм,
Бер ачылыр дөньям, яктырыр.

Күзләреңә багам, алар гүзәл,
Йотып калган алар җәй мәлен.
Күңелеңә керәм, юлларыма
Иң асылын эзлә җәймәнең.

Дөнья миннән башка ага сыман –
Күзалдымда синең күзләрең.
Кышка кереп барыш икән, ә мин
Көз җиткәнен хәтта сизмәдем.

# АК КАНАТ

*(Идиллия)*

Болытларың сагышларга чумган,
Йөри алар күктә аккалап.
Күкләреңә кагылырсың сыман,
Иңнәреңә кунган ак канат.

Күк гөмбәзең биек синең, иркәм,
Канатларың ярсып как тагын.
Бураннарны кузгатырлык икән
Канат кагышларың, аппагым!

Күңел бураннарын кузгатырлык
Көч-кодрәт тә синдә бар икән.
Каурыйларың коела дип торам,
Иңнәреңә кунган кар икән.

## КАРЛЫ ХАТЛАР*

Ап-ак карлар – синнән килгән хатлар,
Кулларыма куна, учыма.
Серле болытлары әйтерсең лә
Меңәрләгән хәбәр очыра.

Кушымта:

Алган саен карлы хатларыңны,
Синең янга күңел ымсына.
Сөю буранына күмәр өчен,
Үзем киләм әле мин сиңа.

Ап-ак карлар – синнән килгән хатлар,
Җавап язам мин дә кар белән.
Бәхет бит ул – сөю уртак булып
Хат алышу сөйгән яр белән.

Кушымта.

Ап-ак карлар – синнән килгән хатлар.
Язлар җитәр, китәр кар-буран.
Болытларга кояш белән урап,
Кочак-кочак хатлар калдырам.

Кушымта.

* Илнар Сөләйманов көе.

## КАПУЛАРЫН АЧКАН ТҮБӘ

Капуларын ачкан бүген зәңгәр түбә,
Буран-буран карлар оча, карлар оча.
Офыкларым тулы өмет балкыса да,
Түзеп карыйм күзләреңә карамыйча...

Түзеп карыйм гүзәллеккә күз атмыйча,
Миңа нәрсә, яусын шунда карлар, очсын!
Акрын гына күңелемә ак төн иңә,
Эзләп йөрим төннәремнең аклаучысын.

Эзләп йөрим төннәремнең ак бөртеген,
Түзеп торам күзләремне йома-йома.
Капуларын ачкан күктән карлар оча,
Өметләрем кары ятсын юлларыңа!

## БУРАНЛЫ КИЧ

*(Идиллия)*

Бураннарның шаяруы бугай –
Аяк асларына кар тулган.
Мин йөгереп барам бертуктамый
Батып барган кояш артыннан.

Бураннарны кочагыма кысып
Үбеп алмак булам, күрәсең.
...Ә син минем гашыйк икәнемне
Күзләремнән генә күрәсең.

Буранлы кич түгел, минем өчен
Күңелемнең алсу таңы син.
Алсуланган йөзләреңнән үбәм –
Хисләремне, бәлки, таныйрсың...

# КЫШКЫ ТӨН

Кышкы айлы төндә, урам буйлап
Туңа-туңа атлап барганда,
Юлда сине күрәм, син киләсең
Бөтерелеп ап-ак карларда:

Йөзең – кызыл алма, керфегеңә
Кунган сыман көмеш тәңкәләр,
Күзкәйләрең синең карга төшкән
Карлыганны хәтерләтәләр.

Иренең – чия...
Гүя кар кызыннан
Җәйбикәгә әллә әйләндең.
Салкын карлы кышым әверелде
Ямьлесенә гүзәл җәйләрнең.

«Кочагыңда миңа урын бармы?
Җәй кызы мин – туңам салкында...»
Сиңа түгел, бар җиһанга җитә –
Минем йөрәк кайнар ялкын ла!

Яп-якты күк. Аймы, йолдызлармы
Җиргә сөю нурын тараткан?
Син бит миңа иң кадерле кеше –
Башкаларны синдәй яратмам!

# БЕЛӘСЕҢМЕ?

*...гә*

Беләсеңме?
Сине күрү көнен
Мизгел санап көтеп алганны,
Очрашуга юллар эзли-эзли,
Йөгерә-йөгерә сиңа барганны.

Беләсеңме?
Әгәр син күренсәң,
Йөрәгемдә учак кабына.
Мин сискәнеп китәм синең сүздән –
Борыч сипкән төсле каныма.

Беләсеңме?
Күзләреңә керсәм,
Күзем ала алмый торамын.
Син бит мине ташкын хискә күмгән
Иң беренче кызы дөньяның.

Беләсеңме?
Ярларына тулып,
Күңлем ташыганын сөюдән.
Мин бәхетле сиңа гашыйк булып,
Сине яратуга сөенәм!

## ӘЙ, АГЫЙДЕЛ СЫЛУЫ! *

Алсу йөзе, җилдәй чәче,
Шомырт кара күзләре.
Ничек мине гашыйк иттең,
Әй, Агыйдел гүзәле!

Әйтче, зинһар, нигә икән
Күңлем хискә тулуы?
Уйларыңда ниләр икән,
Әй, Агыйдел сылуы!

Әйдә, карашларың белән
Зәңгәр күкне гиз әле,
Сине күрсәм, күктә йөзәм,
Әй, Агыйдел гүзәле!

Хисләремне ачыш бирәм
Кыюланып бу юлы:
Мин барыбер сине сөям,
Әй, Агыйдел сылуы!

---

* Гомәр Сәлахов көе.

# ЯШЕЛ ИДЕЛ

## ЯШЕЛ ИДЕЛ

Казан. Бәйрәм. Кемгәдер бәйрәм, кемгә моңсулык... Кешеләр йөри. Юк, бу юлы алар җансыз түгел, аларның җаннары бар! Җан ул – энергия. Әнә ничек музыка ритмына биеп торалар бит. Алар мине күреп сәерсенмиләр дә. Бу вакытта без бер дәрәҗәдә. Мин дә фанилыкка кире кайтам...

Синең җаның бар! Мин моны ачык күрәм. Инде җаныңнан чыгып киттем. Музыка. Халык бии. Ә алар җыр сүзләренә игътибар да итмиләр. Шатлана-шатлана бии бирәләр. Ә бит сүзләре бик моңсу. Кемдер бу сүзләрне минем кебек халәттә язган.

Казан – җанлы! Ике атна элек күргән Уфа түгел инде. Бер карасаң, бөтенесе дә шул ук. Шәфәкъ та, Идел дә... Хәер, Салават Юлаев юк та, Кол Шәриф бар, ай юк. Юк, ялгышам. Әнә ай, хәтта берничә яшел ай. Тагын бер аерма: син юк. Дөрес, син әле чиксезлек дәрьясына чуммадың, күңелдән генә киттең... Онытыласың... Йөрәктә синең исемең белән бәйләнгән ачы тәм генә. Әйе, ачы тәм! Тик берни дә миңа сине оныттырырга теләми: яшел айлар гарәп хәрефләре белән исемеңне тезә, соргылт болытлар шәфәкъ яктысына сурәтеңне төшерергә омтыла. Тирәмдә бөтерелеп йөргән черкиләр дә «Онытма!» дигәндәй, йомшак кына тешләп үтә. Алар тәнемә гашыйк йөрәк рәсемен ясый. Табигать кануннарына каршы барып, акылым артыннан китәм. Мәхәббәт конституцияләрне, кануннарны җимерә, ә Оныту юлыма куелган киртәләрне ватармы? Әлегә мин моңа ышанам! Казан. Җыр. Инде аның сүзләре дә моңсу түгел. Яшел ай! Бер генә. Әйе, бер генә! Чү, бу син түгелме?

Бүген тулган ай йөзеңә генә кунмаган!.. Яшел ай... Тәүбәне бозам, Казан! Гафу ит, Идел, мин Агыйделне күбрәк якын итәм.

...Әнә ул үзе килә. Юк, бу ул түгел, бу син!

Әнә синең хөрмәткә яшел айлар атыла. Алар сыныңнан көнләшәләр бугай... Әллә күзләреңнәнме?..

Мин – татар баласы! Башкалабызда мине барысы да кабул итәчәк. Татарлар да, урыслар да, чувашлар да, башкортлар да, чирмешләр дә, алманнар да, башка чит милләтләр дә, чөнки мин аларны үзем ачык йөз белән каршы алам.

Мин – татар баласы. Һәйкәл куймаслык олы батырлык эшләдемме, юкмы – монысы киләчәк кулында.

Ә киләчәк – синең үткәнеңнең көзгесе.

## КИЧКЕ ШӘҺӘР

Юл буенда гөлчәчәкләр,
Яфраклар, гөлләр кала.
Яңа айның яктысына
Күмелә кичке кала.

Йөгереп барган чагымда,
«Кил!» диеп кемдер дәшәр.
Минем авылчанлыгымнан
Көнләшә кичке шәһәр.

Йортлары йокыга китә,
Күзләрен йома-йома.
Йолдызлар калкырга тели,
Болытлар ера-ера.

«Кал!» диеп берәү дәшәр дә
Күңел түремдә яшәр.
Авыл тулы күңелемнән
Көнләшеп кала шәһәр.

## ШӘФӘКЪКА СЕҢГӘН ЯРЫМАЙ

*(Этюд)*

Шәфәкъка сеңгән ярымай
Ялтырый кайнар күлдә.
Көмеш суның уртасында
Моңлана зәңгәр көймә.

Шәфәкъка сеңгән ярымай
Ни эзли икән судан?
Көндез ай йоклаган таучык
Каралып киткән сыман.

Каралып бара офыклар,
Эңгерне сүтә-сүтә.
...Күлгә төшеп калган айны
Зәңгәр офыклар көтә.

## ҮТЕНЕЧ

Ә син мине көт!
Эзләмә,
Төбәмә күзләреңне.
Мин сагынып көтеп алдым
Ямь-яшел көзләремне.

Мин сиңа киләм!
Көт кенә...
Сизденме күзләвемне?
Сагышларга гына төрмә
Бәхетле көзләремне!

## ОКТЯБРЬ ЯҢГЫРЛАРЫ

Кем кага анда тәрәзгә,
Синме ул, яңгыр, тагын?
...Көтеп ала күңел никтер
Октябрь яңгырларын...

Яңгыркаем, яу син әйдә,
Болытлар әрнемәсен.
Көзгә түгел, кузләргә дә
Кагылсын төнге рәсем.

Кагылсын әйдә күзләргә
Саф яңгыр тамчылары.
Тик, яңгырым, йолдызлардан
Яктырак янчы бары.

Көзге яңгырларга кереп
Быел да бер яз кала.
...Көзге төндә яңгыр булып
Тәрәзгә кояш кага.

***

Ник көз диләр икән бу көннәрне –
Күңелләрдә яна яз гына.
Күбе кирәк түгел,
«Яратам!» дип,
Бер SMS кына яз миңа!

## САРЫ ТҮШЛЕ ПЕСНӘК

Яфрак бураннары үзәгендә
Давыл булыш ярсый хисләрем.
Каршы алам менә алтын көзнең
Соң билгесен – сары песнәген.

Агачлардан бүген кояш ява,
Агачлардан тама көз нуры.
Әллә күзгә күренмичә генә
Көз ялкыны шаулап уздымы?

Көз ялкыны болытларны ялмый,
Әйт, кояшым, бу соң нишләвең?
...Учларыма куныш күккә карый
Сары түшле нәни песнәгем.

## ИҖАДИ КРИЗИС

Фикер дә юк, тема да юк –
Каләм дә юк кулымда.
Уйлар ерак очмак була,
Тәнем белән мин монда.

Җир йөзендә ятыш торам,
Җаным да монда гына.
Киңлек кенә җитеп бетми
Галәмдә уйларыма!

## БӘХЕТЕМ КҮГЕ

Мин сине
бүген дә
Төшемдә күрергә
теләдем.
Гел сиңа
ашкынды
йөрәгем.

Мин сине
кичләрен,
Төннәрен таңнардан
эзләдем.
Гел сине
сагына
күзләрем.

Мин сине
мәңгегә
Калдырдым ялкынлы
күңелдә.
Син минем
бәхетем
күгендә!

## ТӘҮБӘ

Сиңа булган шашкын хисләр
Йөгәнләнсен әйдә!
Кайттым фикер-уйларымнан:
Тәүбә, тәүбә, тәүбә!

Минем ничек яратканны
Сөйлә бәйнә-бәйнә.
– Ул ярата шашып, – диген,
Ә мин әйтәм:
– Тәүбә!

Сүнеп беткән хисләремне
Йөрәгеңә бәйлә!
Мин кайтырмын сиңа, димим:
Тәүбә, тәүбә, тәүбә!

Мәңгелекнең бер көнендә
Калдым шушы хәлдә.
Ярата белмәдем бугай –
Тәүбә, тәүбә, тәүбә!

Тышта яңгыр...
        Йөрәгемә
Син кагасың әнә.
...Үз-үземнән яшеренеп
Тәүбә кылам:
– Тәүбә!

***

Тып-тын гүя.
Бүлмә.
Караңгы.
Тек-тек йөри тик сәгать кенә.
Мин яратмыйм сине. Табалмыйм
Онытырга бер сәбәп кенә.

Таба алмый
йөрдем
һәм таптым
Сагышларның сары җәсәден.
Ә бүлмәмдә тып-тын.
Караңгы.
Тек-тек итеп кенә дәшә төн.

## КЫЗЫЛ УТЛЫ МОРҖА

Кызыл утлы морҗа авызыннан
Күк катына ага ак төтен.
Шул төтенгә карап уйлыйсың син
Бу дөньяның иң шәп егетен.

Кызыл утлар янган морҗаларда,
Төтеннәрдә эреп калма син!
Яфракларга кара һәм күрерсең
Яшел күзләремнең карасын.

Аермыйсың бугай егетләрне,
Аңламыйсың бугай, белмисең.
Хыялыңны читтән эзләп йөрмә,
Сиңа дигән егет – мин үзем!

# КӨЗНЕ КАПЛАГАН КОЯШ

«Девушка освещенная солнцем»
(картина)

*В.А.Серов*

Кояш белән яктыртылган кызый
Гамьле карашларын өләшә.
Өлешеңә тигән көмешеңне
Табар өчен җирдә мең яшә!

Яшә, хәтта дөнья онытса да,
Дөнья онытса да үзеңне.
Син бит үзең күктән җиргә ингән! –
Камаштырсын кояш күзеңне.

Янсын кояш зәңгәр күзләреңдә,
Сеңеп калсын алсу битеңә.
Уттай яна синсез сулган җаным...
Ул тетелә бүген, тетелә...

Мин моңланам, әмма сине беркем
Моңландыра алмый бугай ул.
Сине моңга күмәлмәгән кояш
Алларыңа төшеп моңаер!

Дөньялардан сине таба алмам,
Кояшың да юкса үз инде.
Өлешемә тигән кояшым син –
Калдырып кит миңа көзеңне!

## ЕЛ ЯРЫМ

Күптән сүнәргә үк тиеш иде
Ел ярымга сузылган бу сагыш.
Үткән көннәр онытылган үзе,
Синсез үткән көннәр, әйе, ялгыш.

Мин сагышка инде түзә беләм,
Ул сагышның якты төре генә.
Тик беркөнне бәхет буранына
Төрелергә кирәк, төренергә.

Терелергә кирәк бу чирдән дә,
Сагышлардан тик бер генә дәва.
...Күрәсеңме, күңел бөртегедәй
Ап-ак карлар ява,
ява,
ява.

Ак шомыртлар булып яралды да
Ак карларга әверелде сагыш.
Тоташ ялгышларга күмелсә дә,
Бу бит безнең сөю, безнең язмыш!

Язмышымны мең кисәккә бүлеп
Күзләреңә текәлердәй булам.
...Ап-ак сукмак буйлап сиңа киләм,
Кочагымда – сиңа дигән буран!

## ЭТЮД

Бүген айның күренмәгән көне,
Соңгы сүзне бу төн әйтәсе.
Ай табалмый сүзләр... Җирсылуның
Карга баткан бөтен гәүдәсе.

Айның әле җылынасы килми,
Болыт артларында елышкан.
Шаян җилләр, күлмәк тегәбез дип,
Болыт каурыйларын йолкышкан.

Бүген Җире туй күлмәген кигән,
Әмма Ае никтер күренми.
Ай ул гамьсез, Ай өшегән әнә,
Салкын булгач кач ни, күрен ни?

Туй күлмәген саклап кияр Сылу,
Саклап кына кияр – тапламас.
Беренче кар яуган ап-ак төндә
Ак чәчәкләр аткан алмагач.

Бүген Айның күренмәгән көне,
Әйтәсе шул сүзне, әйтәсе.
...Ак юрганда чагыла оялчан гына
Җирсылуның сылу гәүдәсе.

## КӨЗГЕ НУР

Болытларга тулып көзләр килде,
Тагын җиргә ятты ап-ак томан.
Күңелемдә өмет тулы хисләр,
Әллә нигә син килерсең сыман.

Әйтерсең лә көзнең сагышларын
Күз яшьләре белән яңгыр юган.
Нурга күмеп көзнең моңсу таңын,
Кояш чыга сине көткән юлдан.

## ГӨНАҺ БУЛЫР СЫМАН

Сиңа багышламый шигырь язу
Гөнаһ булыр сыман.
Башка берни таба алмыйм ихлас
Хисләр арасыннан.

Кичермәгән хәлне язып була,
Була ялган язып.
Башкаларга күз сирпү дә миңа
Кичермәслек язык.

Сиңа багышламый гына шигырь
Язу хаҗәт түгел.
Чынлап сөйгәч, башка нәрсә уйлап
Булмау гаҗәп түгел.

Сиңа багышламый гына шигырь
Язып була ансы.
Шагыйрь бара аламыни
Йөрәгенә каршы?!

# УЙЧАН ТӨН

## 1

Төн белән серләшеп ятам мин,
Күзләрне иркәли төн нуры.
Җәяүләп киттеләр уйларым
Көнчыгыш тарафка туп-туры.

Көн белән канәгать булалмый
Йөгәннән ычкынган уйларым.
Күзләрне иркәли таң нуры –
Уйлардан сискәнеп уяндым!

## 2

Төш күрәм, имеш, мин канатлы,
Нигәдер җилпенми канатым.
Аһ, нигә
Мин сине бу кадәр яраттым?

Киселгән канатлар – учымда...
Бу синең канатлар түгелме?
Аһ, нигә
Офыклар очына төн иңде?

Нигәдер җилпенми канатлар –
Җирләргә егылыш төш икән...
Аһ, нигә
Бу миңа кирәсе төш икән?

...Төш күрәм, имеш, мин канатлы,
Нигәдер чык тама канаттан.
Аһ, нигә?..
Мин сине әле дә яратам.

## ТАҢ ҖИЛЛӘРЕ

Таң җилләре нидер дәшә миңа
Чәчләреңне назлап китә дә.
Күзләреңнән тик бер сорау күрәм:
Килерсеңме тагын иртәгә?

Таң җилләре мине озата бара
Карашларың белән янәшә.
Мин килермен, җаным, очып кына,
Күңелеңдә сөю яшәсә.

Таң җилләре миннән нидер көтә,
Серләрнеме сорый, хиснеме?
Бу дөньяда җанны җылытырлык
Сөю булса гына без тере.

Калмагыз сез миннән, таң җилләре,
Канатларым бит сез, моңнарым.
Беркайчан да әле мин бу кадәр
Беркемгә дә гашыйк булмадым.

## 12 ИЮЛЬ, 2006

*(Этюд)*

Көн эссе. Кайнар җилләрдән
Шаулап куйды арышлар.
Челлә челтәрендә кояш
Үзен күккә багышлар.

Ялгышып кычкырды кәккүк
(Сайрамаска тиеш тә!).

Күзне камаштырып, әнә
Ак рәшәләр биешә.

Күкләр офык якларына
Алып китте кыр юлын.
Чәчәк аткан юкәләрдән
Яфрак
        төште
                коелып...

## ҖӘЙСЫЛУНЫҢ ЯШЕЛ ТОЛЫМЫ

Җәйсылуны кочагыма алам,
Юкка чыксын язгы туңуым.
Бөтен күңелемне бирел назлыйм
Җәйсылуның яшел толымын.

Язлар алып китте сагышымны –
Гел мәхәббәт белән тулымын.
Акылымны җуеп иркәлим мин
Җәйсылуның яшел толымын.

Җәй җылы ла – үз сөюем җитәр,
Синсез генә яшәп торырмын.
Чәчләреңнән сыйпаган күк назлыйм
Җәйсылуның яшел толымын.

Безне янә үз янына дәшәр
Безне табыштырган бу болын.
Гөлчәчәкләр белән тарап үрәм
Җәйсылуның яшел толымын.

## ҖИЛӘК

Йөрәктән өзелеп төштең дә
Югалдың ерак китеп.
Тормышым үз урынында,
Бәхетем генә китек.

Кителгән икән кителсен
Минем кырлы бәллүр йөрәк.
Син үбелми генә түгел –
Үрелми калган җиләк!

## ЯТЫП УЙЛАНУ

*(Пародия)*

Мәхәббәттән башны сакламыйк без,
Мәхәббәтне кирәк сакларга!

*Фирүзә Җамалетдинова*

Мәхәббәт ул – ялгыш таеп китеп,
Башың белән төшү ак карга.
«Мәхәббәттән башны сакламыйк без,
Мәхәббәтне кирәк сакларга!»

Мәхәббәт ул – батыр егетләргә
Кинәт кенә «фонарь» кундыра.
Чибәрләрнең егетләре була –
Җир әйләнә шулай тын гына...

Планеталар бар да әйләнәләр:
«Артты, – диләр, – җирдә сак бала...»
Мәхәббәткә берни әрәм түгел –
Башны гына ничек сакларга?

***

Дертләп куйдым, ләкин әрнемәдем
Нурын җуйган йөзләреңне күреп.
Сүреләсең икән, әгәр язмыш
Маңгаеңа терәп куйса күрек.

Сөйгәнеңне югалткансың бугай –
Утыруың иде яшьләр түгеп.
...Хәтеремнең ерак офыгында
Мин дә сине сөйгән идем кебек.

## ГАРМУН МОҢЫ

Гамьсез генә,
Сагышланмый гына
Тыңлап яткан чагың гармун моңын.
Син сөюнең колы гына идең,
Инде аның ханбикәсе булдың.

Гармун моңы гына бәйли бүген
Хисләр кочагына сине, мине.
...Төшләр күрә-күрә гармун уйныйм –
Кушып җырлыйм синең исемеңне.

# КҮЗ ЯШЬЛӘРЕҢ*

*(Җыр)*

Гомеремнең күпме мизгелләре сине уйлап үтте,
Күңелемнең бөтен хисе синең өчен иде.
Сурәтеңне соңгы тапкыр назлап-назлап
үптем, үптем...
Киләчәгем үткәнемне кичерерме?

Кушымта:

Сине уйлап күпме гомер
Узгандыр ул, узгандыр ул.
Күз яшьләрең, бәлки, мине
Кызгандырыр.

Сине эзләп күпме гомер
Узгандыр ул, узгандыр ул.
Күз яшьләрең, бәлки, мине
Кызгандырыр.

Өр-яңадан кайтып киләм синсез үткән гомеремә,
Күңелемнең дөрләп янган чагы үтте менә.
Без ярата алмадык шул мәхәббәтнең бер көнендә.
Йөрәгемдә учак сүнгән. Ул көл генә.

Кушымта.

---

* Рифат Сәлах көе.

## ШУЛ ГЫНА

Күзләрең нигәдер офыкта,
Бәгырең түрендә шом тора.
Бу дөнья шулкадәр гадәти –
Яратам мин сине! Шул гына.

Йөрәгең гөлләргә күмелгән,
Чишмәсе чылтырый тын гына.
Тамчы да көнләшмим. Мин сине,
Мин сине яратам! Шул гына...

## ШАУЛЫЙЛАР

Ишетәмсең, кайдадыр еракта,
Офыклар артында юкәләр
Юралмас хыялга ышаныш,
Гел безне көтәләр.
Көтәләр.

Ишетәмсең, кайдадыр еракта
Калалар артында тупыллар.
Әҗере бетсә дә, сөюгә
Гел дога укырлар.
Укырлар.

Ишетәмсең, кайдадыр еракта
Чәчкәгә күмелгән сириннәр:
«Сөюләр сүнмәскә кабына!» –
Дип юкны сөйлиләр.
Сөйлиләр.

Ишетәмсең, кайдадыр еракта
Мәхәббәт урманы шаулавын.
...Рәнҗемә, китәм мин. Ялгызым
Урманда калмадым.
Калмадым!

## ТЫНГАН ИДЕ КҮҢЕЛ

Тынган иде күңел...
Янә тыныч түгел –
Син шаулаттың аны тагын да.
Мәхәббәтебезнең
Офыклары тулып,
Меңәрләгән кояш кабына.

Тынган иде күңел,
Кара иде күгем,
Күзгә төндәй иде бар дөньям.
Күрәсеңме син дә,
Күңел күгебездә
Меңәрләгән кояш кабынган.

Тынган иде күңел,
Янә тыныч түгел –
Син икәнсең анда һаман да,
Мәхәббәтебезнең
Офыклары тулып,
Меңәрләгән кояш янганда.

## БЕР СӨЙКЕМЛЕ ИТЕП...

Күңелемне тик бер сорау борчый:
Яратасың икән син кемне?
Карашларың шундый якты синең,
Карашларың шундый сөйкемле.

Адашасы иде карашларың
Эчләренә кереп бер генә.
Кояштан да бүген нурлар түгел,
Өмет катыш сагыш бөркелә.

Кояштан да,
Айдан, йолдыздан да
Карашыңны, беләм, тоялмам!
Бер сөйкемле итеп кара да син
Һәм арындыр мине хыялдан.

## НИЧӘ ГАСЫР...

Ничә гасыр, ничә гомер инде
Изаландым, көттем, эзләдем.
Җир өстендә генә булган икән,
Бүген таптым галәм үзәген.

Бөтен галәм төндәй серле икән,
Үзәгендә якты тап кына.
Төнгә күмеп калдырылган серләр
Әверелә анда яктыга.

Әверелер микән яктылыкка
Күңелдәге сүнмәс сагышлар.
...Ничә гасыр, ничә гомер сине
Эзләсәм дә, таптым – язмыш бар!

# ЙОЛДЫЗ КЫЙПЫЛЧЫГЫ

*(Диптих)*

**1**

Карашларың – йолдыз кыйпылчыгы...
Кулларыңнан төшге алсу алма.
Таң кызының толымнары аша
Сиңа бага кемдер, соңга калма.

Уйларымны кабул итәр микән
Йолдызлардан төшкән алтын нурлар?
Керфегеңә кунган йолдыз-чыклар
Тыныч кына җиргә атылырлар.

**2**

Күңелеңнән йолдыз-хыялларың
Атылырлар...
Ә мин китәрмен.

Йолдызыма илткән гөлләремне
Тылсым белән әрем итәрмен.

Чыклар кибәр беркөн,
Офыгыңда
Югалырлар йолдыз-эзләр дә.
Таң кызының толымнары аша
Сөеп багам яшел күзләргә.

# ХАН КЫЗЫ ТИРМӘСЕНДӘ

*(Диптих)*

**1**

Кайда яшисең, хан кызы,
Кай җирдә синең төрбә?
Сайларсың дигән хыял бар,
Өметне өзә күрмә.

Хан егете дә түгел мин,
Түгелмен азгын ишан.
Бөтен күңел бөртекләрен
Сиңа бирермен, ышан!

**2**

Оҗмах бар гүя дөньяда –
Ул синең тирмә генә.
Алыймчы алсу йөзеңне
Күңелем түрләренә.

Җаныңа бер сулыш өрим –
Киңәйсен зәңгәр түбәм.
Каушап калган иренеңнән
Беренче ташкыр үбәм.

## ЗӘҢГӘР ТӨННӘР

Зәңгәр төннәр эреп китәр сыман,
Керфек очларыңа таң кунса.
Бу төннәрем синсез узар иде,
Синнән гүзәлрәк яр булса.

Зәңгәр төннәр ялгыз калыр иде,
Белми калган булсам сине мин.
Көзге җилләр белән очар иде
Офыкларга җитәр сөюем.

Зәңгәр төннәр сагынырлар сине,
Без көзләргә кергән чакларда.
Җәйге болыннарны сагынганда,
Син килеп кит безнең якларга.

Син килмәсәң әгәр, үзем барам,
Канатына кунып җилләрнең.
Юлларыңа сирин чәчкәләрен
Зәңгәр төннәр итеп сибәрмен!

***

Минем сүнеп барган күңелгә дә
Янә кар сулары ташып тулды.
Сиңа диеп язган шигырьләргә
Башка ярлар шашып гашыйк булды.

Сиңа диеп язган җырларыма
Бер пәрдә юк бүген – ачык томан.
Тик нигәдер бүген сиңа түгел,
Сиңа дигән җырга гашыйк булам!

## ЮКТЫР...*

Сөю моңы күмде күңелемне.
Мин ышанам йөрәгеңдә уттыр.
Айга менеп карасам да,
Бөтен җирне айкасам да,
Бу дөньяда сиңа тиңнәр юктыр.

Төннәреңне күмсен бәхет нуры,
Сагышыңны җил иркенә очыр!
Сагышлардан сула күрмә,
Яшә генә йөрәгемдә,
Бу дөньяда сиңа тиңнәр юктыр.

Мәхәббәтең күмде бар дөньямны:
Күкләремә салдың алтын күпер.
Син яктырак кояштан да,
Син гүзәлсең мең яздан да –
Бу дөньяда сиңа тиңнәр юктыр.

Атылганда нәни йолдызчыклар,
Очкын бул да җанга бәхет тутыр!
Бар хисләрем сиңа гына,
Яныш яшә, сула гына!
Сине миндәй яратучы юктыр.

* Илшат Сәлахов көе.

## КИРӘКМИ...

Кирәкми миңа машина,
Кирәкми акбүз атлар.
Аякларым йолдызларга
Җәяүләп кенә атлар.

Йолдызлар бәйләмен сиңа
Бирермен кочак-кочак.
Ни булыр хисләрне күккә
Чәчәкләр итеп койсак?

Чәчәкләр генә янарлар,
Чәчәкләр генә явар.
Чәчәкләргә тиң хисләрне
Йолдыз итү дә ярар!

Кирәкми миңа машина,
Атлар да, беләм, арыр.
...Йолдызларны күккә чәчеп,
Йөрәгем сиңа барыр!

## МӨРӘҖӘГАТЬ

Син сүзләрнең тәмен белеп яздың,
Ә мин белеп яздым гыйшык тәмен.
Фәлсәфәгә тулган сүзләреңнән
Сөюемә җавап ишеткәнмен.

Карлыгачтай кыйгач кашларыңның
Канатында бергә очу – өмет.
Фәлсәфәле юллар сырла, булсын
Тәкъдимемә җавап ишетерлек!

## СИН КАЙТЫРСЫҢ КЕБЕК

Кыр казлары тавыш бирә кабат,
Шул җырларны язын тыңладым.
Күзгә болытларда
Офыкларга
Агып киткән язмыш юлларың.

Яз гөлләре гөрләп чәчәк ата –
Сәлам бирә күчмә кошларга.
Ничек итеп безнең язмыш юлын
Өр-яңадан бергә кушарга?

Саубуллашып тормыйм синең белән,
Син кал әле минем күңелдә.
Күзләренә карыйм чәчәкләрнең –
Сары күзләр генә күренә.

Яз гөлләре гөрләп чәчәк ата,
Чәчәкләрнең бирим кайсысын?
Күчмә кошлар күзен киткән юлдан
Син кайтырсың кебек, кайтырсың.

## ШИФАХАНӘ

*(Шаяру)*

Мәхәббәтсез генә ничек
Тамырда каным аксын?
Миңа кирәк бераз гына
Витаминнар һәм аксым.

Мәхәббәтсез генә ничек
Буында җилек булсын?
Авырыйм бугай, җаныма
Шифалы дару бул син!

Агу гына була күрмә,
Күңелнең тамыры тар.
Мәхәббәтнең йөрәк аша
Дөрләтеп узасы бар.

Мәхәббәтсез генә ничек
Хисләрем тулсын, ташсын?
Миңа да витамин кирәк,
Түгел бит мин дә таш сын.

Миңа да мәхәббәт кирәк,
Салкын тидерә күрмә!
Карашларың минем өчен
Операцион бүлмә!

## ХЫЯЛ КҮГЕ

*(Этюд)*

Карлыгачның балалары сыман,
Сихри зәңгәрлеккә очындык.
Җирнең тарту көче җиңде безне –
Ай-һай кырыс икән бу чынлык!

Тамчы булып кызыл нурлар тамды
Хыял канатлары очыннан.
Бәллүр йөрәк җиргә тәгәрәде
Бераз гына туңган учымнан.

## ЯЗМЫШ ВАГОНЫ

Ни кылсам да, онытмассың мине!
Үткәнеңне сагын-сагынма.
Алсу таңнар белән бергә иңдем
Хыял төсендәге вагонга.

Күзләреңнән тик бер сорау көтәм:
Йөрәгеңдә сөю калдымы?
Икебезнең хисләр белән генә
Тулган икән язмыш вагоны.

Ә син ерак... Вокзалда да түгел,
Түгел поезд барган тарафта.
Бәхет кенә өләшермен дисең,
Яратырмын, ярат-яратма.

Язмыш канунына буйсынасың,
Аңа нәрсә: оныт-онытма.
Ике сумка сөю төяп киттем
Зәңгәр вагон очкан офыкка.

# БҮЛӘК

Адашырга җиңел кыш килгәнче,
Кирәк, имеш, байлык, төрлелек.
Туң-бозларны эретергә тели
Җан очына кунган бер өмет.

Ай бу тиле йөрәк күпне тели,
Бәхетне дә кайчак азсына.
Күңелдәге чәчәкләрдән үргән
Мәңге шиңми торган яз сиңа!

# ЯЗГЫ АЛМА

Тулып пешкән кызыл алма булып
Бит очыңа кунган бар хисең.
«Күрешүләр вакытлыча гына,
Яннарымнан китмә, кал!» – дисең.

Бит очларың – тулып пешкән алма,
Йөрәгеңдә калды бар хисем.
Күрешүләр вакытлыча була,
«Гомерлеккә генә кал!» – дисең.

# ЯЗ АХЫРЫ

Ә мин сине яратмаска булдым.

*Газинур Морат*

Яз ахыры...
Көннәр үткән язның
Соры өннәренә охшаган.
Яшеллеккә төрә-төрә җанны,
Китеп барам карлы кышлардан.

Ә мин сине онытырга булдым,
Хәтеремдә генә калырсың.
Язларыңнан китеп, мине көткән
Язларыңа таба барырсың.

Яз ахыры миңа әллә нигә
Хәтерләтә моңсу күз алдын.
...Ә мин сиңа кагылалмам инде –
Яннарыңнан гына узармын.

Яз ахыры...
Тик мин үткән язның
Соры өннәренә охшамам!
Могҗизалар булмый җирдә,
Беләм,
Тик бу язга күбрәк ышанам!

# БӘСЛЕ ИРТӘ

Бу кышлар тынмас күңелне
Әллә кайларга илтә.
Тәрәзгә килеп сарылган,
Сагынган бәсле иртә.

Сагынган сыкы, тәрәзне
Үзенә урап алган.
Иртәнең хуш исе аңкый
Сукмакта яткан кардан.

Иртәнең хуш исе аңкый –
Бәс исе килә бүген.
Тупыллар сыкы-каешка
Буганнар нечкә билен.

Каеннар бәсле иртәдә
Такканнар энҗе сәйлән.
Түбәдән кар бөртекләре
Коела берән-сәрән.

Бу кыш шундый суык, ләкин
Күңелгә җылы кертә.
Кояшка килеп сарылган,
Сагынган бәсле иртә.

## ЗАЯ ҮТКӘН КӨН

*(Халәт)*

Синең янга киттем.
Берни дә юк,
Өмет тә юк сиңа күңелдә.
Берни кылмадым мин,
Мактаналмыйм,
Зая үтте бүген көнем дә.

Ял иттем мин бүген
Бу тормыштан.
Иртә иде... инде ай чыкты.
Күңел – төпсез бушлык...
Бу тормышка
Кагылмау да кирәк кайчакта.

## УЙ-ДӨНЬЯМДА

Уй-дөньямда начар фикерләр юк,
Уй-дөньямда тик саф уй гына.
Кемнәр ялган сөйли: күңел тарткан,
Сөйгән кеше, имеш, туйдыра...

Вәгъдәләргә, дөрес, иртә әле,
Ләкин сиңа төште күңелем.
Йолдыз булып күкләремдә балкы,
Кояш итеп сине күрермен!

# БӘСЛЕ КЫШ*

*(Идиллия)*

Кыш өстенә ап-ак тунын кигән –
Бәскә тулган кышның бу туны.
Бүген яуган ап-ак карлар әллә
Безгә дигән бәхет булдымы?

Ап-ак карлар тылсым гына түгел,
Бәхет кенә түгел ул бүген.
Бәсле тунын кигән кыш каршында
Бәсле керфегеңнән үбүем.

Кыш өстенә бәсле тунын кигән,
Сиңа биргән бөтен бизәген.
Ирен очларыңа ак кар кунды –
Өзелергә тора үзәгем.

---

* Рифат Сәлах көе.

## ХЫЯЛ

Бүген кояш тагын батып бара,
Бүген дә шул кояш һәр көнге.
«Ә иртәгә башка кояш чыгар,
Син көт аны!» – диеп әйтерме?

Хыялыңа тагын дәшеп кара,
Кояшыңа җылы өстәп тор.
Сиңа язлар өләшергә теләп,
Кояшың да туңа – кышта ул.

Сиңа язлар өләшергә тели,
Ул үзгәрәк булыр иртәгә.
Әгәр синең язмышың ул икән,
Каршылык та булыр, киртә дә.

Күңелеңә өмет өстәп торыр
Кояш баткан якта ал томан.
...Мин иртәгә таң беленгән мәлдә
Юлга чыгам кояш артыннан.

## КОЧАГЫМДА ПЫШЫЛДЫЙСЫҢ

Син бит минем карлы болытларга
Ай-йолдызлы күкләр биргәнсең.
Якын итә алыр дисең мәллә
Синнән башкаларның берәрсен?

Синең белән танышканнан бирле
Йолдыз яңгырында коенам.
Тышта салкын. Чыгасы да килми
Беразга да синең куеннан.

## ТӘҮГЕ ОЧРАШУ

Күзләреңнән күрәм моң-дулкыннар –
Күзләреңә күпме наз кирәк...
Бер кагылып китсәм, нурланасың,
Күңелеңдә бүген яз, димәк.

Күзләреңә якты нурлар иңә,
Кочагыма кыскан чагында.
Син ерак та түгел икән миннән –
Күкрәгемдә минем, җанымда.

Ничек инде җылы бирми була
Шундый иркә, шундый назлыга?!
Яннарыңа килгән чакларымда
Күңелеңдә булсын яз гына!

## АВЫЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЧИБӘРЕ

Яныңа йөгереп килүем
Тирбәтер күңелең кылларын.
Мин туган җиремдә
Авылның
Беренче егете булмадым.

Әллә соң син салган очкынны,
Нәрсәдер җилкетә йөрәкне.
Сиңа тиң булырга
Авылда
Беренче булу да кирәкме?

Үзгәреп булмас шул, мин сиңа
Бүгенге җан белән ымсынам.
Күңелне тирбәтеп торасың
Сүрелмәс бер дәртле моң сыман.

Син туган җиреңдә
Авылның
Беренче сылуы идеңме?
Мең егет йөргәндер татырга
Иң асыл, иң татлы иренне.

Яныңа йөгереп килүем
Ак пәрдә – ак офык артыннан.
Котыпта кебек ул синсезлек,
Җылытчы бер генә – җан туган.

Җылытчы бер генә җанымны,
Бер авыл башында күрен дә.
Авылның беренче егете
Булмадым мин туган җиремдә.

Син туган якларда тумадым,
Күрмәгәнмен синең кебекне.
Югыйсә буласы идем бит
Авылның беренче егете.

## ТЫШТАН ГЫНА...

Тыштан гына салкын күренәм мин,
Күңелемә сөю салдың, моң...
Беләсеңме икән, бердәнберем,
Юксындым мин сине, сагындым.

Күңелемдә кар-бураннар гына
Бүген туган иртә шикелле.
Ак канатлы җилләр хисләремне
Синең янга илтә шикелле.

Бу кышлар да тыштан гына шундый,
Тиңе түгел алар салкынның.
Туңгансыңдыр, кил, җылытыйм әле,
Мин сагындым, иркәм, сагындым.

Күккә карап нигә юксынасың –
Кояш качкан кышның күгеннән.
Күрәсеңме, сиңа дигән хисләр
Ак бураннар белән күмелгән.

Ак буранга сагышларны түгел,
Бәхетләрне генә салырмын.
Җаннарыма меңләп сагыш кунган,
Бик сагындым, җаным, сагындым.

Күзләреңне йомма миңа карап,
Уйлый күрмә, түгел төш кенә.
Кочагымда сиңа дигән җылы,
Күңелемдә – кайнар хис кенә.

Тыштан гына шулай күренәмен,
Тыштан гына шулай сабырмын.
Күрәсеңме, яннарыңа киләм,
Сагындым мин сине, сагындым!

## БЕРАЗГА...

Яз күленә керең чумган дөнья:
Күкләр – аяз, күкләр – күгелҗем.
Саф хисләрем ап-ак карлар белән
Агып китәр, менә күрерсең!

Ә син әле кышлар кебек салкын,
Карашларың тулы боз һаман.
Сукмакларым язлар аша үтә,
Җәйге назлар эзләп кузгалам.

Күңелеңдә буран түгел микән,
Тәрәз аръягында кыш барда.
Бу кышлар да йомшак күңелле шул –
Әверелеп ята тушларга.

Хәятыңда нидер, син беләсең...
Сер бирмәссең хәтта сөйсәң дә.
Йөрәгемә җәйләр генә өләш,
Сөю кимеп бара иңсәмдә.

Эреп барган сөю кушылырмы
Ташу-елгаларга бу язда?
Юлга чыгар өчен юлдаш эзлим,
Сине көтеп торам беразга.

Котышларда җәйләр көтсәң әгәр,
Бушка гына үтәр бер гасыр.
Үзем белән җырлы җәй иләнә
Сине алып китми булмастыр!

Сине алып китми булмас шул!!!

## КЫШ ЯШЬЛӘРЕ

Юлымда кыш елый,
Тар бушлыкта
Туган авылыма кайтып барам.
Язасым да килми –
Каләмемнән
Чишмә сыман ага зәңгәр карам.

Юлымда кыш елый.
Автобусның
Тәгәрмәче кар яшьләрен ера.
Сорауларың калса,
Җавап эзләп,
Таш каланың йортларыннан сора!

Соры йортлар
Җавап табалмаслар –
Җавапларын язлар юды инде.
Юлымда кыш елый...
Алларымда
Чәчәкләнгән язлар юлы инде.

## ЯЗЛАРЫМА КАЙТАМ

Тынмас күңел белән кергән кыштан
Тыныч кына ничек чыгасың?
Язын-көзен дөрләп торган йөрәк
Бер өшесен дидем, чыдасын!

Сүнгән килеш, күнгән килеш кенә
Җир өстеннән китү юк ары.
Өметләрем һаман офык әле,
Хыял-пәрдәм һаман югары.

Аклык-сафлык нигә салкын икән...
Яшеллеккә китәм, җылыга.
Май сукмагы буйлап атлап барам,
Күмелдем дә кошлар җырына.

Үткән икән, хәерлегә булсын! –
Бәсле иртә бирде кирәген.
Күңелемә кунган кояш белән
Язларыма кайтып киләмен.

## ЯЗГЫ ТАЛПЫНУ

Синнән генә яраттырыр идем,
Мәхәббәттә әгәр булса көчем.
Кочагымда шаулап чәчәк аткан
Яз күтәреп йөрим бүген кичен.

Белсәң икән ярсу күңелемнең
Ташкыны да, ялкыны да шул ук.
Сиңа дигән саф сөюем булып
Кочагымда чәчәк ата шомырт.

Мәхәббәткә тигән сагышлардан
Эреп беткән миндә күңел кары.
«Яратмыйм мин сине!» – дигәч тә син,
Күңелемдә күпме сөю калды.

Ошатып та чынлап яратмаган
Ярлар өчен тормыш алды үчен.
Яз буенча сине эзләп йөрим
Шомырт чәчәкләре бирер өчен.

## ЯЗГЫ ИДИЛЛИЯ

Язны көтеп, назлы итеп
Салмак кына җил өрә.
Тәрәзәдә гөлләр көлә,
Баганалар җилдерә.

Ак чыршылар, ак каеннар
Кала миңа күз атып.
Җил иңенә утырткан да
Куя гүя озатып.

Болытлары да юк бүген –
Күге аяз көн менә!
...Тәрәзәгә тиеп йөри
Ак канатлы җил генә.

***

Күзләреңә бер карыйсым килә,
Күмеләсем килә карашыңа.
Чык бөртеге булып тамар идем
Юлыңдагы гөлләр арасына.

...Күзләреңә бер карыйсым килә,
Чагылыйм дип күзең карасында.
Синең җылылыкны тоеп яшим
Сагыш белән бәхет арасында!

## ЭЧТӘЛЕК

Шигъриятнең киләчәге. *Л.Шәех* . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

**Яшел ай нурында**

Яшел ай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Гыйбадәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Болгарым! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Археологик экспедиция . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Уяну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Әй Русия! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Үз телеңдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Исхакый! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Сәйдәш музеенда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Мөфти хәзрәткә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Бәйсезлек турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Таркаулык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Чебен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Постмодерн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Бүген . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Зиндан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Бәхет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Ураза гаете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Уртак түбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Гарәпләрдән күреп... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Сүриядә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Барып җитәрме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Сәяхәтнең бер көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Дәмәшкъ күгендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Шам илендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Дәмәшкъ капкалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Кальгатүл Мәркәб тәэсирендә . . . . . . . . . . . . . 28
Вокзалда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Югалттым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Сагындым сине, әнием! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Туган туфрак җылысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31

Гарәп гүзәленә . . . . . . . . . . 31
Тәрәзәң төбендә . . . . . . . . . . 33
Саубуллашу . . . . . . . . . . 33
Are you...? . . . . . . . . . . 34
Казан . . . . . . . . . . 35
Туган авылыма . . . . . . . . . . 35
Сориле . . . . . . . . . . 36
Кайтып киләм сиңа, мәктәбем! . . . . . . . . . . 37
Мәхәббәтнамә . . . . . . . . . . 38
Төнлә . . . . . . . . . . 38
Эндәшмәгез!.. . . . . . . . . . . 39
Бөек шагыйрьгә . . . . . . . . . . 40
Шагыйрь күзләре . . . . . . . . . . 40
17 май, 2007 . . . . . . . . . . 41
«Җир йөзендә гомер сөргән...» . . . . . . . . . . 41
Көрәш . . . . . . . . . . 42
Басу . . . . . . . . . . 43
Тозсыз боткадан соң... . . . . . . . . . . 43
Туган көнең белән, әнием! . . . . . . . . . . 44
Ришвәт . . . . . . . . . . 45
Йокла, энем! . . . . . . . . . . 45
Тамчы-яз . . . . . . . . . . 46
Шәһәр ваклыклары . . . . . . . . . . 50

**Яшел Агыйдел**

Яшел Агыйдел . . . . . . . . . . 52
Яз гүзәленә . . . . . . . . . . 53
Кирәк миңа... . . . . . . . . . . 53
Паркта . . . . . . . . . . 54
Табыш . . . . . . . . . . 54
«Ак каеннан эскәмия...» . . . . . . . . . . 55
Сиренле челтәр . . . . . . . . . . 56
Сиринле мәхәббәт . . . . . . . . . . 56
Канатыңны салдың учыма . . . . . . . . . . 57
Җаннарыбыз бертуган . . . . . . . . . . 58
Күпләр сиңа гашыйктыр . . . . . . . . . . 59
Сора әле!.. . . . . . . . . . . 59
Таң туганда . . . . . . . . . . 60
Кагыл әйдә, кагыл җаныма! . . . . . . . . . . 61
Акланырга тиеш . . . . . . . . . . 61
Саф кызга . . . . . . . . . . 62
Яныңа барам тагын . . . . . . . . . . 63
Туган көнең белән котлар өчен... . . . . . . . . . . 64
Туйда . . . . . . . . . . 65

Юкә исе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Кая югалдың син, Зилә? . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Сүрелмә, кояшкаем! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Өмет йолдызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Сәлам белән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Гарәп мөдәррисәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Иренеңдәге миңең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Нишлисең анда? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Уфа төне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Кабыз! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Егерменче таң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Дингездә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Күңел бөртекләре – 2 . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Өзелмәсен алсу иртәләр . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Таш бәгырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Калды микән?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
«Күңелеңдә кайнар учак булсын...» . . . . . . . . . . 78
Күзге күбәләкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Күз буләге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Миләш тәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Видагъ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Миләшем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Мәхәббәт каршында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
«Сагыныр мине бу йортлар...» . . . . . . . . . . . . . 83
Сандугач белән хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Хушлашырга вакыт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Яратып тор... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Кичерсәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Еладың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Онытмадым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Күзләреңә багам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Ак канат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Карлы хатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Капуларын ачкан түбә . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Буранлы кич . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Кышкы төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Беләсеңме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Әй, Агыйдел сылуы! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94

**Яшел Идел**

Яшел Идел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Кичке шәһәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Шәфәкъка сеңгән ярымай . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Үтенеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

Октябрь яңгырлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
«Ник көз диләр икән бу көннәрне...» . . . . . . . . . . . . . 100
Сары түшле песнәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Иҗади кризис . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Бәхетем күге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Тәүбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
«Тып-тын гүя...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Кызыл утлы морҗа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Көзне каплаган кояш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Ел ярым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Этюд . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Көзге нур . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Гөнаһ булыр сыман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Уйчан төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Таң җилләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
12 июль, 2006 . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Җәйсылуның яшел толымы . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Җиләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Ятып уйлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
«Дертләп куйдым, ләкин әрнемәдем...» . . . . . . . . . . . 113
Гармун моңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Күз яшьләрең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Шул гына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Шаулыйлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Тынган иде күңел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Бер сөйкемле итеп... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Ничә гасыр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Йолдыз кыйпылчыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Хан кызы тирмәсендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Зәңгәр төннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
«Минем сүнеп барган күңелгә дә...» . . . . . . . . . . . . 120
Юктыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Кирәкми... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Мөрәҗәгать . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Син кайтырсың кебек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Шифаханә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Хыял күге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Язмыш вагоны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Бүләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Язгы алма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Яз ахыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Бәсле иртә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Зая үткән көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Уй-дөньямда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129

Бәсле кыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Хыял . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Кочагымда пышылдыйсың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Тәүге очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Авылның беренче чибәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Тыштан гына... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Беразга... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Кыш яшьләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Язларыма кайтам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Язгы талпыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Язгы идиллия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
«Күзләреңә бер карыйсым килә...» . . . . . . . . . . . . . 138

Литературно-художественное издание

**Салах** Рифат
(**Салахов** Рифат Галиевич)

**ЗЕЛЕНАЯ ЛУНА**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Сәлах** Рифат
(**Сәлахов** Рифат Гали улы)

**ЯШЕЛ АЙ**

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире
*Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.10.2009.
Форматы 70×90 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 5,2.
Тиражы 2000 д. Заказ В-1518.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.